Инвалид арбасында – сәяхәткә

«Авариягә юлыкмаган булсам, бүген нәрсә белән шөгыльләнер идем икән? Мөгаен, эчүемне, тартуымны дәвам иткән булыр идем. Хәзер тормышка башкача карыйм. Ни булуына карамастан, оптимист булып калам. Күңел төшенкелегенә бирелгән инвалидларны да саздан чыгарырга тырышам. Аракы эчеп, проблемаларның хәл ителмәгәнен аңлатам».

10 БИТ

Байлык культы

Матди байлыкны күз уңында тотып әйтелә торган «Акыллы булгач, ник бай түгелсең?!» дигәнрәк бер тәгъбир бар. Бу татар сүзе түгел. Татарда акыллыны кимсетү, ахмакны данлау омтылышы юк. Башка бик күп нәрсәләр кебек үк, урыс аша кергәндер инде. Ләкин ничек кенә булмасын, бу сүз бик тәвәккәл яңгырый, игътибарны яулый һәм дөреслек кебек тоела. Чынында ул шыр ялган, дөреслеккә якын да килми.

11 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри Казан

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 23.03.2017 | № 30 (5792)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

«ХӘЙРИЯЧЕЛЕК МИНЕМ ӨЧЕН – ХОББИ»

– «Үзенчәлекле балалар өчен җиһаз» проектын без 2013 елда башлаган идек. Шушы вакыт эчендә меңнән артык баланы махсус урындыклы иттек. Бу искиткеч күрсәткеч, моның артында бик зур хезмәт тора. Әшебезнең ни дәрәҗәдә масштаблы булуын чагыштырып өчен әйтеп күрсәтим: дәүләт Россиянең берничә субъектындагы инвалид баланы шушы кадәр урындык белән бер ел тәэмин итә. Әле бу ярдәмне алыр өчен бик күп документлар җыярга, мең катлы бюрократия юлларын узарга кирәк, – ди Рөстәм Хәсәнов.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

7 БИТ

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга 66 сум 99 тиен

3 айга 200 сум 97 тиен

6 айга 401 сум 94 тиен

Ташламалы бәядән язылып кал!

Һәр айның 15 числосына кадәр язылсагыз, газета киләсе ай башыннан киләчәк.

Синең өчен, синең турында!

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

136 сум 15 тиен 1 айга

408 сум 45 тиен 3 айга

816 сум 90 тиен 6 айга

Реклама

РЕСПУБЛИКАДА

АКСУБАЙ

Аксубай районының Түбән Татар Майнасы авылында «Көнбатыш Кама аръягы торак пунктлары тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү проблемалары»на багышланган фәнни-гамәли конференция үткән. Чарада йөздән артык туган якны өйрәнүче һәм тарихчы катнашкан. Конференциядә Америка Кушма Штатларының Висконсинск университеты профессоры, тарих фәннәре докторы Юлай Шамилуглы да чыгыш ясаган.

ӘЛКИ

Әлки районы Алпар урта мәктәбенең 9нчы сыйныф укучысы Анар Масимов милли көрәш буенча Россия чемпионатында юниорлар арасында өченче урын яулаган. Чемпионат 16-19 мартта Башкортстанның Стәрлетамак шәһәрендә узган. Районның яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге белгечләре әйтүенчә, ил күләмендәге бу җиңү – Әлки тарихында беренче.

ЧАЛЛЫ

«Чаллы хәбәрләре» газетасын укучы Әдип исемле кеше Чаллыда трамвай һәм автобусларда тукталышларны татар телендә дөрес хәбәр итмәүләренә борчыла. Ул редакциягә: «Яңа вагоннарда аудиоязмада тукталышларның дөрес әйтелмәвенә игътибар иттем. Мәсәлән, 9нчы трамвай. Ир-ат тавышы рус телендәгесен дөрес җиткерә. Аннан хатын-кыз тавышы, һәм диктор «киләсе тукталыш» дип әйтми. Шуннан буталыш китә. 6нчы трамвайга күчеп утырдым, анда да шул ук хәл. Яңа автобуслар буенча да сораулар бар. Тукталышларны дөрес хәбәр итмәгәндә, кәеф кырыла. 2015 елда ук мэриянең транспорт идарәсенә шалтыратып әйткән идек, төзәтәбез диделәр, үзгәреш юк», – дип хәбәр юллаган.

АЗНАКАЙ

Азнакайлылар дүрт якташлары – шагыйрьләр Флёра Гыйззәтуллина, Марсель Галиев, Нур Әхмәдиев һәм Илдус Гыйләҗев белән берьюлы очрашу бәхетенә ирештеләр, дип яза район басмасы. Мәдәният йортында әдипләрнең олуг юбилейлары уңаеннан уздырылган кичә сәнгать осталарының җыр-биюләре, әдипләрнең чыгышлары, район җитәкчелеге, «Маяк» газетасы каршында эшләп килүче «Гөлстан» әдәби берләшмәсе, мәдәният, мәгариф учреждениеләре коллективлары котлаулары белән үрелеп барган.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

КЕМ ГАЕПЛЕ?

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Дәүләт Советының чираттагы утырышында төп игътибар Татарстан премьер-министры Илдар Халиковка юнәлтелгән иде. Ул республика башкарма хакимиятенең 2016 елгы эшчәнлегенә хисап тотты. Депутатлар, һәрвакыттагыча, күптөрле сораулар яудырды, «Татфондбанк» темасы да игътибардан читтә калмады.

Линар ЗАКИРОВ

Узган ел икътисади яктан никадәр авыр булмасын, Татарстан, барлык киртәләрне үтеп, яшәешнең күп кенә тармакларында югары күрсәткечләргә иреште. Әйтик, былтыр 55 853 нәни татарстанлы дөньяга аваз салган.

Халыкның яшәү шартларын яхшырту өчен, экология темасына да зур игътибар бирелә. Мисал өчен, 2016 елда 36 районда 43 парк тәртипкә китерелгән. Быелгы Экология елында да шәһәрләрдәге, район үзәкләрендәге сулыкларны чистартачаклар, торак һәм юл төзелеше өлкәсендә яшел стандартлар күбрәк кулланылачак.

Илдар Халиковның 40 минутлык чыгышыннан соң сүз депутатларга бирелде. «Коммунист» Артем Прокофьев «Татфондбанк»ның ни сәбәпле төпкә китүе белән кызыксынгач, премьер-министр:

– Сораулар үзебездә дә күп. Ни өчен Үзәк Банк, карарын соңгы мәлдә генә кабул итеп, безгә алданрак хәбәр итмәде. Ни өчен Ernst&Young халыкара аудиторлары ел саен банк эшчәнлеге буенча әзерләнгән хисапка уңай бәя бирде? Ни өчен халыкара рейтинг агентлыклары «Татфондбанк»ка югары рейтинг билгеләде? – дип, үзенең дә күпсанлы сораулары барлыгын җиткерде.

Илдар Халиков әйтүенчә, бүгенге көндә иң мөһим мәсьәлә – кертемчеләргә акчаларын кайтарып бетерү.

– Халыкны да, мине дә, Хөкүмәтне дә борчыган «Кем гаепле?» дигән сорауга хокук сакчылары гына җавап бирә алачак. Әмма аңардан да әһәмиятлерәк мәсьәлә – мондый хәл киләчәктә кабатланмасын өчен, нинди чаралар күрергә? – дип кабат сорауларын тезде премьер-министр.

Билгеле булганча, Президент күрсәтмәсе нигезендә, кыен хәлдә калган эшкуарларга ярдәм күрсәтелә. «Татфондбанк» белән «Интехбанк»та акчасы «бикләнеп», ярык тагарак алдында калучыларга төрле шартларда бер миллиард сум чамасы акча бирелгән инде.

СӘЯСИ КӘЛИМӘ

Разил ВӘЛИЕВ,
Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе:

– Унбер ел буе мәктәптә рус һәм татар телләрен тигез күләмдә өйрәнгән укучыларыбызның күбесе нәтиҗәдә өч сүзне кушып татарча җөмлә төзи алмый. Без еш кына: «Баланың теле гаиләдә ачылырга тиеш», – дибез. Бик дөрес сүзләр. Әмма бүгенге гаиләләрдәге ата-аналарның яртысыннан күбрәге үзләре дә татар телен белми. Шулай булгач, алар ничек итеп балаларының телләрен татарча ача алсыннар ди?

Татарстан Конституциясе буенча бары тик бер вазифаи зат – Президент кына ике телне белергә бурычлы. Президент белгәч, ә ни өчен премьер-министрга, Дәүләт Советы рәисенә, депутатларга, министрларга, хакимият башлыкларына, гомумән, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләргә андый таләп куелмый? Дәүләт телен белмәгән дәүләт хезмәткәре дөньяның тагын кайсы илендә бар

Шәһәр кәефе

РӘМЗИЛ ГАРИПОВ,
телеоператор:

– Казанның Киров районындагы «Ягодная слобода» бистәсеннән үзем. Без уйнап үскән ишегаллары юк инде хәзер. Тораклар сүтелеп, юл салдылар. Шул тирәләрдән узганда, элеккеге йортлар күз алдыма килеп баса. Күңел моңсулана. Шәһәр төзелешенең үз кагыйдәләре. Эштән кайткач, вакыт балалар белән мәш килеп уза. Хыялым – балаларны сәламәт итеп үстерү. Җыйнаулашып Финляндиягә сәяхәт кылырга да исәп бар.

АЛИНА БЕРЕЖНАЯ,
журналист:

– Тумышым белән Коми республикасының Воркута шәһәреннән. Югары уку йортын Казанда тәмамладым. Казан бик ошады, шунлыктан биредә калдым. Татарстаннан Воркутага поездда өч тәүлек кайтырга кирәк. Казан – Воркута авиарейсы ачылсын иде дип телим. Европа илләрендә булдым, чиратта – Кытай. Кемдер спорттан тәм таба, ә мин ял көннәрендә мәдәният сараена бию түгәрәгенә йөрим.

ФӘКЪЛИЯ МӘРСИНА,
пенсионер:

– Әлки төбәгендәге Иске Чаллы авылы баласы мин. Казанга килгәнемә 50 елга якын. 30 еллап нәшрияттә эшләдем, газеталар бастык. Җилкенеп эшләп йөргән чаклар үткәндә калды, картая төштек. Сагышларга бирелеп, бетәшеп утырган юк. Аллага шөкер, туган якларга да кайтып килгәлибез. Татар җырларын тыңлау – үзе бер юаныч. Дөньялар тыныч-имин булсын иде! Безгә өлкәннәргә инде җитә, яшьләр эштән өзелмәсен.

ЗИМФИРӘ БИКТАШЕВА,
рәссам:

– Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы буларак, мин иҗат белән яшим. Язда тугач, табигатьнең шушы чорын бик яратам. Казанның Мөштәри урамында үстем. Юкә, алма, чия чәчәк атканда, һәркем шул урамнардан бер узсын иде. Сара апа Садыйковадан күреп, «Мин дә бит татар кызы» дип, 15 яшемдә калфак кигән идем, әле дә салганым юк. Бик яратам шулай йөрүне. Җәй көне башкалабыз урамнарында калфаклы ханымнарны күбрәк күрергә өметләнәм.

ИЛДАР ХӘСӘНОВ,
юрист:

– Казан – туган шәһәрем. Хезмәт юлым транспорт тармагында узды. Декабристлар урамында «Яшьләр үзәге» белән «Гуманитар институт» автобус тукталышлары арасы ике чакрымга якын. Өлкән яшьтәгеләр өчен бик уңайсыз. Декабристлар – Чистай урамнары чатында, ягъни урталыкта тагын бер тукталышны рәхәтләнеп ясарга була. Декабристлар урамындагы 8нче һәм 10нчы йортлар ишегалларында балаларга уен мәйданчыгы юк.

икән? Мәсәлән, Израильдә дәүләт телен өйрәнмәсәң, хәтта урам себерүче булып та эшкә урнаша алмыйсың.

Роза ЖАББАРОВА,
Татарстан Дәүләт Советы хатын-кыз депутатларының «Мәрхәмәт» берләшмәсе:

– Соңгы елларда икенче һәм өченче бала туу очраклары арта. Әмма демографик рекордлар хөкүмәт алдына яңа бурычлар куя – сабыйларга балалар бакчалары һәм мәктәпләр кирәк. Президент программасы нигезендә тормышка ашырыла торган бакчалар төзелеше программасы ярдәмендә, өч яшькә җиткән балаларны бакчаларга урнаштыру мәсьәләсе хәл ителде дияргә дә була. Әмма бер-өч яшьлекләрне балалар бакчалары белән тәэмин итү мәсьәләсе көн кадагыннан төшми. Хәзерге заманда барлык әниләр дә нарасыйлары белән өч яшькә кадәр өйдә утыра алмый. Бер ише, яшәргә акчасы җитмәгәнлектән, эшкә иртәрәк чыгарга мәҗбүр, тик балаларын кая урнаштырырга белмиләр.

Хафиз МИРГАЛИМОВ,
КПРФ фракциясе җитәкчесе:

– Республикада сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү буенча зур эш башкарыла. Әмма белгечләр җитеп бетми. Тагын бер «авырткан җиребез» – түләүле хезмәтләр. Әгәр дәүләт югары технологияле медицина җиһазларын салым түләүчеләр акчасына ала икән, ни өчен шул ук кешеләр хезмәтләрне уткән өчен түләргә дә тиеш?

Белгеч эштән соң медицина җиһазында авыруны тикшерә икән, бу очракта табибның хезмәтенә генә түләнергә тиеш. Алай иткәндә, түләүле хезмәтләрнең бәяләре 2-3 мең сум түгел, күпкә арзанрак булыр иде. Җитмәсә, җылылык, ут һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү медицина учреждениесенең бюджетында каралган.

Урта медицина персоналының хезмәт хакы 24 мең сумны тәшкил итә, шуның 10 меңе төнлә дежур тору өчен каралган. Медицина хезмәткәрләре шул акчага биш көн буе сигез сәгать чамасы эшләргә тиеш. Мондый шартларда гаиләне карау, балаларны тәрбияләү, башка төрле рухи ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен каян, ничек вакыт табарга?

vk.com

Бәхет төшсә ишелеп!

Самарада яшәүче Николай атлы берәү лотереяга 54, 46 млн сум акча откан. Әлеге ир-атка бәхет Яңа ел алдыннан ишелеп төшсә дә, киң җәмәгатьчелеккә бу турыда әле шушы көннәрдә генә билгеле булды.

– Түбән Новгородка эш буенча баргач, дусларга һәм өйдәгеләргә бүләккә дип, алты билет сатып алдым. Бишесен башкаларга өләштем, ә берсен үземә калдырдым. Шунысы кызык: әлеге билет миңа бөтенләй дә отышлы сыман тоелмады. Ә үземнең шушы кадәр акча отуымны белгәч, аңлатып бетерә алмаслык хисләр кичердем, – дип искә ала бәхетле ир.

Николай сүзләренчә, ул откан акчасын нәрсәгә тотачагын әлегә кадәр хәл итмәгән. Әмма аларның бер өлешен иганәчелеккә тотачагына бер минут та шикләнми. Ә сез зур күләмдә акча отсагыз, аны нишләтер идегез?

Зөлфәт ЗИННУРОВ, алып баручы, җырчы:

– Ооо, рәхәтләнер идем мин! Иң элек йортны бик купшы итеп эшләп бетерер, койма тотар, гараж салыр, гөлбакча утыртыр идем. Туганнар, дуслар белән рәхәтләнеп ял итәргә тагын бер шәп беседка ясасам да артык булмас. Аннан калганына берничә фатир сатып алыр идем, әмма бер тиенен дә банкка салмас идем, чөнки аларга ышаныч юк. Соңыннан инде, әлбәттә, бик яхшылап, дөньяларны онытып, чит илгә чыгып ял итәргә генә кала.

Гөлинә АБДУЛЛИНА, дүрт бала әнисе:

– Бу турыда күз алдыма китерәм дә, акылдан язудан куркам! Әгәр шундый бәхет насыйп булса, башта шок булыр иде, аннан соң сөенечтән кычкырып бер елар идем. Соңыннан гына акчаны нәрсәгә тотарга икән, дип уйлый башлармын сыман. Иң элек булган бөтен кредитларны каплар идек, аннан соң шәһәрдән читтә зур, матур, бакчасы да булган йорт, берничә фатир, яхшы машина һәм балаларны йөртер өчен микроавтобус сатып алыр идем. Аннан соң бөтен гаиләбез белән сәяхәткә чыгып китәрбез кебек. Аннан да калса, акчаларны берничә банкта бүлеп саклар идем.

Сөләйман ШАКИРОВ, газета укучы, 81 яшь:

– Үземә берни дә кирәкми. Акчаларның бер өлешен хәйриячелеккә тотар идем. Мохтаҗларга ярдәм булсын дип, авыл мәчетенә тапшырыр, әти-әнием, туганнарымның каберлекләрен тиешенчә яңартыр идем. Аннан калган акчаларны онықларыма бүләргә була. Аларның укуларына, әс-башларына да бик күп кирәк бит.

КҮРШЕЛӘРДӘ

БАШКОРТСТАН

«Башинформ» агентлыгы хәбәр итүенчә, җирле халык урамнарда үлгән яки яраланган кошларга тап булган. Эстәрлетамак телевидениесе мәгълүматларына караганда, аларда юлларга сибә торган реагентлар составына кергән химикат кисәкчекләре табылган.

– Кошларның ашказанындагы химик-токсикологик тикшерү анда хлоридларның 0,37 процент булуын күрсәткән. Бу нормадан 1,5 тапкыр артык һәм ул кошларның агулануына китергән, – дип сөйләгән белгеч Юлия Мясина.

ЧУВАШИЯ

Чувашия суднолары җәйге навигациягә әзерләнә. Алар маршрутка май башында чыгачак. Хәзерге вакытта суднoларга техник хезмәт күрсәтелә. Аеруча машина бүлеге эшчәнлеген һәм идарә итү системасын диагностикалауга зур игътибар бирелә.

МАРИ ЭЛ

Узган ел Мари Элның Пенсия фонды яше җиткән 44 кешегә пенсия билгеләүдән баш тартырга мәҗбүр булган. Бу хокуктан мәхрүм булганнарның күбесе – Йошкар-Олада яшәүчеләр. Моның сәбәбе гади – яңа кабул ителгән закон буенча, хәзер пенсиягә чыгар алдыннан баллар һәм хезмәт стажы исәпкә алына. Бу очракта кайсысына – баллар, кайсысына стаж җитмәгән.

АТНА ФОТОСЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

ТОП – 5

РОССИЯ Президенты Владимир Путин Россия Мөселманнары үзәк диния нәзарәте рәисе Тәлгат Таҗетдин белән илнең мөселман өммәте эшчәнлеге мәсьәләләре хакында сөйләшкән. Бу турыда ил башлыгы матбугат сәркатибе Дмитрий Песков хәбәр итә.

– Россиянең дини конфессияләре вәкилләре белән даими аралашуын дәвам итеп, Президент Россия Мөселманнары үзәк диния нәзарәте рәисе мөфти Тәлгат Таҗетдинне кабул итте. Очрашуда сүз мөселман өммәтенең агымдагы эшчәнлеге хакында барды, – ди матбугат сәркатибе.

ТЕХНИК җайлау һәм метрология буенча федераль агентлык Россиядә эшләп килгән хәләл туристлыкның ирекле сертификациясе белән бәйле кагыйдәләр стандартын теркәде. Бу ислам кануннарын саклаучы мөселманнар өчен туристлыкны оештыруда өстәмә мөмкинлекләр ача. Россия кунакханәләрендә хәләл стандарт проектын тормышка ашыру, Россия мөфтиләр советы кунакханәләр бизнесы вәкилләре белән берлектә, 2016 елның августында ук башланган. «Хәләл» халыкара стандартлаштыру һәм сертификатлаштыру үзәгенең генераль директоры Айдар Газизов әйтүенчә, хәләл кунакханәләрдә кешеләр һәм хайваннар сыны һәм сурәтләр юк. Бу кунакханәләр Коръәннән тәрҗемәләр, намазлыклар, хәләл туклану белән тәэмин ителә. Намаз укыганда белү өчен изге Кәгъбә юнәлеше дә күрсәтелгән була.

БЕЛГЕЧЛӘР, мәктәп яшендәге балалары булган гаиләләр ярлылык дәрәҗәсе чигендә санала, дип белдерә. Бу хакта Россиядә балага туугa ярдәм чараларын тикшерүләр күрсәткән. Аларны Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясенең Социаль анализ һәм фаразлау институты галимнәре үткәргән.

УЗГАН елның феврале белән чагыштырганда, быел россиялеләрнең акчалата реаль кереме 4,1 процентка кимегән. Бу хакта Россиянең социаль-икътисади хәле турындагы Росстат докладында әйтелә, дип хәбәр итә Российская газета. Моңа да карамастан, реаль хезмәт хаклары ел әйләнәсендә 1,3 процентка арткан, ә 2017 ел башыннан үсеш 2,3 процент тәшкил иткән. Росстат мәгълүматлары буенча, түләнгән уртача хезмәт хакы – 35,9 мең сум. Бу – узган ел күрсәткечләреннән 6 процентка югарырак.

1 МАЙДАН 1 октябрьгә кадәр чорда сезонлы (җәйге) кафеларда алкоголь продукциясен ваклап саткан очракта, сатып алучыларга зал булдыру таләбе куелачак. ТР Дәүләт Советы депутатлары шуңа бәйле закон проекты кабул итте. Аның нигезендә, стационар булмаган җәмәгать туклану объектларында ваклап сатуга рөхсәт ителгән алкоголь продукциясе исемлегенә дә киңәйтелә. Хәзер җәйге кафеларда сидр, пуаре һәм әче бал сату да рөхсәт ителәчәк. Элек бу сыра һәм сыра эчемлекләренә генә кагыла иде.

Авыл ялкауларны сөйми

Артур Хәбибуллин белән мин татар авыллары эшмәкәрләре җыенында таныштым. Ул – Лениногорск районының Ормышлы авылыннан. Әтисе Фәнзат Хәбибуллин 2004 елда ук крестьян-фермер хуҗалыгы ачкан. Әлеге эштә аңа уллары Артур, Азат һәм оныклары булыша. 18 сыердан башланган хуҗалыкта терлекләрнең баш саны бүген 450гә җиткән. Хәбибуллиннар үзләре Ормышлыда яшәсә дә, терлек фермалары күрше Яңа Елхово авылында урнашкан. Пай җирләреннән тыш, мең ярым гектар җирләре бар. Аны районнан 15 елга арендага алганнар. Кырда үзләренә җитәрлек көзге бодай, солы, арпа чәчәләр.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Былтыр сатуга дип көнбагыш, карабодай утырттык. Быел 100 гектар җиргә рапс чәчәргә уйлыйбыз. Ә менә кукуруз, борчакны сатып алабыз. Ике сенаж базы, складлар төзеп куйдык. 2010 елда гаилә фермаларын үстерү программасы буенча 1 миллионлык грант алдык. Дүрт фермабыз бар. Соңгы ике елда аларны төзекләндерү өчен безгә башта 600 мең, аннары 1 миллион 200 мең сум күләмендә акчалата ярдәм күрсәтелде. Дәүләт фермаларга керү юлын бетон белән түшәп бирде. Маллар сатып алганда да субсидияләрдән файдаландык. Эшлим дигән кешегә булышлык күрсәтәләр, тәвәккәлләргә генә кирәк, – ди Артур.

Хәбибуллиннар авыл кешеләрен дә эшле иткән. Алар кул астында бүген 18 кеше эшли, җәйге-көзге чорда 25кә җитәләр. Әмма шул ук вакытта белгечләргә дә кытлык бар икән.

– Нефть ягы булгач, кадрлар белән авыррак. Күп яшьләр нефть тармагына китә. Авыл хуҗалыгы белгечләре юк. Әйтик, безгә үз ветеринарыбыз, зоотехнигыбыз кирәк. Белгечләрне үзебезгә җәлеп итәр өчен йортлар салып, аларны авылга кайтарырга ниятлибез. Купмедер елга килешү төзеп, эшләп китсәләр, киләчәктә өйләрне үзләренә дә калдырырга уйлап торабыз. Хуҗалыкта баш кеше – әти. Ул безнең агроном. Энем Азат механик вазифасын башкара, транспортны ремонтлау, карап тору аның өстендә. Мин исә күбесенчә документлар белән эш итәм. Авыл җирлеге башлыгы булып та торам. Улларыбыз җәй көне көтүгә чыгалар. Гаиләдә һәр кешегә эш җитәрлек, барысы да тигез бүленеп куйган. Икенче улым киләчәктә ветеринар булыр дип торам. Әтинең эшен дәвам итәргә дәвамчылар да булачак, – ди Артур.

– Авылда калырга теләрләрме икән? – дигән соравыма ул:

– Хәзер авылда да менә дигән итеп яшәп була. Шәһәрдә фатир арендалап торганчы, рәхәтләнеп авылда үз өеңдә яшисең. Авылдагы тормышны элеккеге белән чагыштырып булмый хәзер. Утын әзерлисе, су ташыйсы юк. Дөресен генә әйткәндә, ялкаулык көчәеп китте. Ә авыл ялкауларны сөйми ул. Эшлим диючегә эш табыла. Авыл кешесе гомер буе мал тоткан. Мал асрап, беркемнең дә оттырганы юк. Итқә, сөткә һәрвакыт ихтыяҗ бар һәм булачак, – ди әңгәмәдәшем.

Былтыр «Безнең авыл» бәйгесендә җиңүчеләрнең берсе – Бакырчы авылын котларга баргач, халыкның бердәмлеген, кунакчыллыгын, активлыгын күреп сокланып кайткан идек. Ул чакта без төп иганәчеләр – бертуган Бәхтияровлар ярдәме белән төзелгән «Суфия» мәчете ачылышында да катнаштык. Шөкер, мәчет бусагасына тузан төшми. Узган елларда анда зур чара – «Дин галимнәре эзләреннән» дип аталган бәйге узды. Анда 1-9нчы сыйныф укучылары Коръән сүрәләре укуда үзләренең мөмкинлекләрен күрсәтте, шәригать кануннарына кагылышлы сорауларга җавап бирде.

Автор фотосы

Динле булган, телне белгән

Эльвира МОЗАФФАР,
Яшел Үзән, Бакырчы – Казан

Бакырчы чагыштырмача кечкенә авыл, анда 100ләп хуҗалык исәпләнә. Шуңа да карамастан, мәчетнең буш торганы юк. Ирле-хатынлы Рәшидә абыстай белән Әнәс хәзрәт, Хәлимә абыстай атнага ике тапкыр балаларга, олыларга дин сабаклары укыта. Үзе дә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе укучысы булган Рәмис Шәйхуллин якшәмбе көннәрендә шәкертләргә белем бирә. Мәчеттә 22ләп бала шөгыльләнә. Дини дәресләргә күрше авыллардан да теләп йөриләр. Гатауллиннар Бакырчыдан биш чакрым ераклыктагы Сунчәләй авылыннан атнага ике тапкыр мәчеткә укырга киләләр икән. «Көн саен йөрергә дә риза», – диләр үзләре. Мәчеткә аяк басуларына кызлары Регина сәбәпче булган. Башта ул дин сабаклары ала башлаган. Аннары үзе артыннан сигез яшьлек сеңлесе Рүзиянә, әтисе-әнисе Радик белән Илүзәне дә ияртқән.

– Ислам диненә якынаю турында күптәннән хыяллана идем. Шөкер, мондый мөмкинлекләр бар. Мәчеттә җиде төрле фән укыйбыз. Укулар бик кызыклы, мәгънәле бара. Дин кушканча яши башлагач, тормышыбыз уңай якка үзгәрде. Күңелендә булса, барына да вакыт табарга була, – ди Радик Гатауллин.

Бакырчы шәкертләре бәйгеләрдә еш катнаша. Коръән сүрәләрен укып, Казанда узган «Сөембикә энеләре һәм сеңелләре» бәйгесендә дә җиңү яулаганнар. Үзләрендә дә бәйгеләр еш була. Ә менә мондый киң масштабта зурлап уздырулары әле беренче генә тапкыр. Бәйгедә 80нән артык шәкерт катнашты. Араларында Яшел Үзән районыннан гына түгел, Кайбыч, Апас якларыннан да балалар бар иде. Биш яшьлек Әминә Азлуханова Чабаксардан ук килгән. Сүрәләрне аңа әтиәнисе өйрәтә икән. Бәйгедә катнашучы егетләр-кызлар үзләре мондый чараларны бик тә кирәкле дип саный.

– Мәктәптә дәресләр күп булса да, сүрәләр өйрәнергә вакыт табабыз. Бәйге вакытында күп кенә сорауларга хәзрәтләр аңлатма бирде,– ди шәкертләр.

Балаларның дини белемнәрен Яшел Үзән, Кайбыч районнарыннан килгән дин әһелләре бәяләде. Яшел Үзән районының мөхтәсибе Габделхәмит Зиннәтуллин: «Мондый чаралар туган телне саклауда да зур әһәмияткә ия», – дип саный.

– Дәүләткә дә ике телне белгән белгечләр кирәк. Туган телне өйрәнмичә, Президент та, министр да булып булмый. Авылда туган гыйлемле, ислам динен акларлык шушы шәкертләрне шәһәргә дә җибәрерсез дип көтеп калабыз, – диде хәзрәт.

Аның сүзләрен Бакырчы авылы мулласы Әнәс хәзрәт Закиров та хуплады. Ул: «Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә мәчеткә юлны күрсәтсен иде», – дип теләде. Кайбыч районының Ябалак авылының имам хатибы Айрат Кәлимуллин Бакырчы үрнәгендә үзләрендә дә балаларны җыеп, аларга дин сабаклары өйрәтергә җыена. Теләк белдерүчеләр җитәрлек икән. Кайбыч районында 16лап мәчет исәпләнә. Аның тугызында дини дәресләр алып барыла. Кайбыч районы мөхтәсибе Дамир хәзрәт Гыйниятуллин фикеренчә:

– Белгәннәребезне балаларга өйрәтү бурычыбыз булып тора. Өйрәтмәсәк, динебез сүнәргә мөмкин. Учакка утын өстәп торганда гына ул яхшы яна. Дин алымнарын өйрәнә башлаган балаларның да гыйлемнәрен арттырып торырга кирәк. Киләчәктә мөселман таблар, җитәкчеләр булса, бер дә начар түгел. Күңелендә дин булган кеше гадел, намуслы була. 20 ел элек үзебезнең Кайбычта дин сабакларын укырга теләүчеләр күбрәк иде, кызганыч, бүген компьютер, телевизор баларны диннән тартып алырга тырыша. Шуңа да бу өлкәдә кызыксындыру чараларын күрү мөһим, – ди Дамир хәзрәт.

– Сүрәләрне иң камил, төгәл башкарган шәкертләргә: Әмир Исмәгыйлев, Алия Зәйнуллина, Нәфис Хәялиев, Ләйлә Хәйретдинова, Әлфия Шагиева, Җәмилә Гыйниятуллина һәм башкаларга мактау кәгазьләре һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды. Гомумән, мәчеттән бер бала да буш кул белән китмәде. Ахырдан барлык кунакларны 200 кешегә әзерләнгән табынга чакырдылар. Кыстый-кыстый кунак та итмәгәч, бакырчылылар була димени! Авылның уңган киленнәре, аппалары гадәттәгечә сыгылып торган табын әзерләгән иде. Милли киемнәрдәге җитез кызлар һәркемне яннарына килеп сыйлады. Бакырчылыларның бу эшләре дәвамлы булсын.

sovch.chuvashia.com

Җирнең кадастр бәясе: кайда һәм ничек?

Укучыларыбызның җир кишәрлекләренең кадастр бәясен билгеләү мәсьәләләренә кагылышлы сорауларына «Консалтинг һәм бәяләү» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры Васыйл Мәҗитов җавап бирә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Хәзерге вакытта җир салымы участокның кадастр бәясеннән чыгып исәпләнә. Гражданнар, авыл хуҗалыгы оешмалары, җир участоклары хуҗалары үз җирләренең кадастр бәясен белү өчен нәрсә эшләргә тиеш?

Гөлинә ХИСАМОВА,
Арча.

Моның өчен үзегез белергә теләгән җир участогының кадастр номеры гына кирәк. Ә аны җир участогының кадастр паспортыннан яки җиргә хуҗа булу таныклыгыннан табарга мөмкин. Моның өчен башта Интернетта Росреестрның кадастр картасы битенә керергә кирәк (Публичная кадастровая карта). Аннан соң кадастр номеры, адрес, координатлар битенә кызыксындырган җир участогының кадастр номерын кертеп эзлисең. Килеп чыккан биттә әлеге җир участогы турында күп кенә мәгълүмат, шул исәптән кадастр бәясен дә белергә була.

Җирнең кадастр бәясе ничә елга бер тапкыр исәпләнелә? Аның бәясе нәрсәгә бәйле?

Алсу ХӘЛИМОВА,
Казан.

Җир өчен яңа бәя кую закон нигезендә өч елдан да иртә, биш елдан да соңга калмыйча башкарылырга тиеш. Җирнең кадастр бәясе ул кишәрлекне нинди кулланылышта файдалану өчен рөхсәт бирелүгә, кайда урнашуына карап куела. Шәһәр яны җирләре, төрле оешмалар, офислар урнашкан, файдалы казылмалар булган җирләр авыл хуҗалыгы карамагындагы җирләрдән күпкә кыйммәтрәк йөри. Юлларның кадастр бәясе, киресенчә, арзанрак. Шәһәр һәм авыллардагы һәр кишәрлек кадастр бәясен алгач, урындагы депутатлар ставкалар кабул итә. Әгәр физик затлар өчен ул 0,5 процент булса, юридик затларга – 1,5 процент. Шәһәрдә җир участокларын куллану рөхсәт ителгән объектларның берничә төре бар: рөхсәт ителгән торак йортлар, спорт заллары, «Ашыгыч ярдәм» станцияләре, хастаханәләр, административ предприятиеләр, офислар, конторалар, транспорт чараларын даими һәм вакытлыча саклау урыннары, вакытлыча куелган вак сәүдә корылмалары, коммуналь хуҗалык объектлары (электр, жылылык, газ, су белән тәэмин итү һәм башкалар), тукталышлар һәм гаражлар, балалар мәйданчыклары, ял итү һәм спорт белән шөгыльләнү урыннары, чүп савытлары мәйданнары һәм башкалар.

Әгәр миндә кадастр бәясе шик уятса, кая да булса мөрәҗәгать итә аламмы?

Илнур ГАЯЗОВ,
Казан.

Әйе, сез алты ай эчендә дәгъва белдерә аласыз. Аны махсус комиссия хәл итә. Бүгенге көндә мондый комиссия Казанда Татарстан буенча Росреестр идарәсендә эшли. Комиссияләрнең эшчәнлеге турында тулырак мәгълүматны, элемтә өчен телефон номерларын идарәнең рәсми сайтыннан карап карарга мөмкин. Әгәр аның аша узмасагыз, Арбитраж судына мөрәҗәгать итәргә туры киләчәк. Комиссия яки суд кадастр бәясен түбәнрәк дип тапкан очракта, салым түләүче бәяне яңадан карауны сорап гариза биргән көннән башлап, салым суммасын кабат исәпләттерә ала. Әмма күп очракта җир хуҗалары участокның яңа бәясен салым оешмаларыннан түләү кәгазе килгәч кенә белә һәм шунлыктан әлеге вакытны югалталар. Шуңа күрә, бәхәс килеп чыкмасын өчен, салым түләүчеләрнең алдан ук милек объектларының кадастр бәясен белеп торуы яхшы. Ә аны «Росреестр» сайтыннан, объектның кадастр паспортыннан һәм Кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән белеп була. Җирнең кадастр бәясеннән чыгып салым, аренда бәяләренең суммалары исәпләнә.

Россиядә, шул исәптән Татарстанда да кадастр бәясе буенча сорауларның күп булуын ишетеп беләм. Бу хакта Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов та: «Татарстанда ике категория караклар бар – ришвәт алучы түрәләр һәм кадастр бәясен төшерүчеләр», – диган иде. Моннан кала, эш барышында тагын нинди проблемалар ачыклана?

Илсум ГАБДРАХМАНОВ,
Казан.

Бу очракта бераз гына үзебез турында да әйтеп узасы килә. Без – Россиядә иң тәҗрибәле оешмаларның берсе. Төрле төбәкләрдә – Мурманск, Архангельск, Иркутск, Красноярск, Кырым, Төмән, Чувашия, Мари Эл, Калининградта эшләп, ун млн объектны бәяләдек. Бу вакытта шактый проблемалар булуы ачыкланды. Мәсәлән, җир кишәрлекләренең формалашкан чикләре булмау, төзелеп бетмәгән объект чикләре белән җир участогының чикләре киселү, җир чикләрен билгеләүдәге техник хаталар, саклаулы зонага (урман фонды) кергән җирләрдә рөхсәтсез төзелешләр, бүлеп бирелмәгән участокта төзелешләр һәм башка шундый закон бозу очраклары ачыклана. Чынлыкта, Татарстанда салым түләнелми торган җирләр бик күп. Аеруча шәһәрләрдә территорияләрне биләп алу шактый. Эшне уңайлы итү максатыннан, 15 мартта «Җир» ситуация үзәге старт алды. Аның үзенчәлеге нидә соң? Киләчәктә бу программа тулы куәтка эшләп киткән очракта, Россия буенча бөтен мәгълүмат бер урында тупланачак: законнардагы үзгәрешләр турында аңлатма һәм Росреестр, Кадастрлар палатасы, салым органнарының мәгълүмат базасы. Акрынлап барлык хаталарны ачыклыйбыз һәм аларны кулдан эшләп чыгачакбыз. Кабатлап әйтәм, бу – эшләрне күпкә җиңеләйтәчәк. Хәзерге вакытта, мәсәлән, билгеле бер участоктан җир сатып алырга теләгән кеше, газ торбасының әлеге тирәдән узу-узмавын, участок саклаулы зонага керү-кермәвен белү өчен, берничә урынга мөрәҗәгать итә. Ә алардан җаваплар төрлесе төрле вакытта килә. Шуңа күрә киләчәктә әлеге бөтен мәгълүмат бер урында булачак. Берничә елдан бөтен мәгълүмат бергә туплангач, анда кулланылган эш тәҗрибәләрен Россия төбәкләрендә дә кулланып булыр дип көтелә. Җир мәсьәләләрен тирәнтен өйрәнү хисабына салым керү ике тапкырга артачак, әмма башка проблемалар да хәл ителәчәк. Мондый тәҗрибә Мәскәү өлкәсендә кулланыла инде. Дөрес аңлагыз, моңа кадәр салымнарын намус белән түләп барган гади халык өчен моның куркынычы юк. Алар болай да тиешенчә түли, гадәттә, байлар һәм эре предприятиеләр түләми. Моңа кадәр әлеге мәсьәлә әледән-әле күтәрелсә дә, артык игътибар бирелмәде. Хәзерге вакытта административ ресурслар бу мәсьәләне ахырга кадәр җиткерү дәрәҗәсенә җитте, дип саныйм. Безнең максат та – идарә итү системасын үтә күренмәле итү һәм шуның белән кешеләргә җиңеллек тудыру.

Росреестрның кадастр картасын төзү өчен нинди эшләр башкарыла?

Альбина АБДУЛЛИНА,
Биектау .

Иң элек Кадастрлык палатасы бәя куелырга тиеш булган барлык җир кишәрлекләрен билгели, төркемнәргә бүлә, базарга анализ ясый, газеталарда басылып чыккан белдерүләрне җыеп анализлый, кыйммәтле һәм арзанлы кишәрлекләрнең картасын төзи. Быелдан бу эш белән дәүләт бюджет учреждениеләре шөгыльләнергә тиеш. Алар Россиянең һәр төбәгендә формалаша.

Сәхифәбезнең киләсе темасы социаль ипотека программасына багышланачак. Кызыксындырган сорауларыгызны **(843) 562-50-03, 562-50-12** телефоннары аша редакциябезгә юллый аласыз.

ҖИРНЕҢ КАДАСТР БӘЯСЕ КУЛЛАНЫЛГАНДА, ҖИР САЛЫМЫ НИЧЕК ИСӘПЛӘНЕЛӘ?

Кадастр бәясе (сумнарда) × Процент ставкасы × Җирле үзидарәләр тарафыннан билгеләнгән коэффициент күтәрү = САЛЫМ СУММАСЫ

ҖИР САЛЫМЫ БУЕНЧА ТҮБӘНДӘГЕ КАТЕГОРИЯ ГРАЖДАННАРГА ТАШЛАМАЛАР КАРАЛГАН

✓ Советлар Союзы һәм Россия Геройларына, Дан Орденының тулы кавалерларына;
✓ 2004 елның 1 гыйнварына кадәр инвалидлык алган I һәм II төркем инвалидларга;
✓ хезмәт эшчәнлегенә өченче дәрәҗә чикләүгә ия I һәм II төркем инвалидларга;
✓ балачактан инвалидларга;
✓ Бөек Ватан сугышы ветераннарына, инвалидларына һәм тыл хезмәтчәннәренә.

Түбәндәге категория гражданнарга салым базасы бер муниципаль берәмлек территориясендә бер салым түләүчегә салым алына торган сумманың 10 000 сумын чигереп исәпләнә.

✓ чернобыльчеләргә;
✓ әфганчыларга;
✓ 1994 елның декабреннән 1997 елның гыйнварына кадәр Чечен Республикасында һәм Россиянең Чечен Республикасы чигендә урнашкан, сугышчан конфликтлар зонасына кергән территорияләрендә хезмәт итүчеләргә.

Өстәмә ташламаларны җирле үзидарәләр эшләргә мөмкин. Казанда, мәсәлән, шәхси йортта яшәүче күп балалы гаиләләр җир салымын түләми. 400 квадрат метр җир өчен Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм ветераннары, шул исәптән сугышчан хәрәкәтләрдә катнашкан ветеран һәм инвалидлар, I һәм II төркем инвалидлар, тумыштан инвалид булган, Чернобыльчеләр шулай ук салым түләүдән азат ителә.

ЯЗЫЛГАНГА КИРЕ КАЙТЫП

Илдусның үз фатирында яшисе килә

Укучыбыз Миңлегөл апа Әдһәмова редакциябездә еш була. Гадәттә ул газетада күтәрелгән берәр темага карата фикерен белдергән язмаларын алып килә. Бу юлы борчуы йөзенә үк чыккан иде. Миңлегөл апаның озак еллар дәвамында абыйсының авыру улы Илдусны каравын күптән беләбез. Илдусның төп нигезе – әти-әнисеннән калган йорты (Питрәч районы, Шәле авылы) бик тузган. Питрәч районы хакимиятенә торак шартларын яхшырту ниятеннән документлар җыеп тапшырса да, әлегә бернинди үзгәреш юк, ди Миңлегөл апа. Ә егетнең бик тә үз фатирында яшисе килә. Илдусның әнисенең язмышы да аяныч булган икән. Бу хакта да Миңлегөл ападан ишетеп белдек.

Эльвира МОЗАФФАР

Илдусның әнисе Мәчтүрә апа кечкенәдән авырлыклар күреп, ярлы тормышта үсә. Әтисе сугышта һәлак булган. Тапканнары очны-очка ялгап барырга гына җитә. Әни назын да озак тоярга насыйп булмый Мәчтүрәгә. Каты авырудан савыга алмыйча, гүр иясе була әниләре. Сеңлесе белән үз көннәрен үзләре күреп яши кызлар. Сеңлесе кияүгә чыккач, Мәчтүрә ярым җимерек йортта берүзе кала. Колхозда эшли. Тырышлыгы нәтиҗәсендә, гел алдынгылар рәтендә була. Танышлары күрше авылы егете Низамга (Миңлегөл апаның абыйсы) димләп кияүгә бирәләр. Яңа йорт җиткерәләр, тату гына гомер итәләр. Тормышлары җайлангандай була. Тик күпме көтсәләр дә, балалары тумый. Ходайга ялварулар, күз яшьләре, өметсезлек... Ниһаять, биш ел дигәндә, Мәчтүрә балага уза. Тик көтеп алган ир бала гарип булып дөньяга килә: сөйләшми, бер аягы кыска, бер кулы хәрәкәтләнми. Ничек кенә булмасын, ата-ана бирдәнбер күз нурын яратып, тәрбияләп үстерә. Күршеләре әле дә искә алалар икән, Мәчтүрә апа: «Бу бала үлсә, зираттан да кайтмам, түзә алмам», – дия торган булган. Тик малаена кадәр үзе гүр иясе була.

2003 елның 30 августы. «Мәчтүрә югалган» дигән хәбәр Шәле халкын аякка бастыра. Ире Низам абый сөйләвенчә, бар кеше йоклап беткәч, Мәчтүрә апа мал-туар карарга дип, абзарга чыккан булган. Ире аңа, төн уртасында хайваннарны куркытып йөрмә, дип, керергә кушкан. Иртә белән уянса, өйдә Мәчтүрәсе юк. Хатын аңа кадәр дә башы авыртудан зарлана торган булган. Кайвакыт хәтере дә югалган. Әмма улын карыйсы булгач, хастаханәгә барырга, дәваланырга вакыт тапмаган. Бу юлы да өянәге кузгалган булган, күрәсең.

– Мәчтүрә апаны авылда озак эзләделәр. Тирә-юньдәге авылларны да айкап кайттылар. Аны эзләүләре турында игъланнар да элделәр. Дүрт-биш көн узгач кына Питрәч район үзәгенә үле гәүдәсен китерәләр. Мәчтүрә апаның үлеме безнең өчен бүген дә сер булып кала. Халык арасында: «Лаешка баручы берәү машинасына утыртып киткән икән», – дигән сүзләр дә йөрде. Имеш, Кун авылында бер баракка килеп эләккән икән, дип тә сөйләделәр. Хәтта, үз үлеме белән үлмәгәндер, дип тә шикләнәбез. Дөреслекне табасы иде, – дип өзгәләнә Миңлегөл апа.

Бу вакыйгага шактый еллар узган инде. Мәчтүрә апа вафатыннан соң Миңлегөл апа абыйсына инвалид улын карарга ярдәм иткән. Низам абый да үлеп киткәч, малай тулысынча Миңлегөл апа карамагында калган.

– Абыем вафатыннан соң опека органнарыннан килделәр. Ул чакта Илдуска 38 яшь иде. Хастаханәгә, махсус үзәккә тапшырмыйсызмы, диделәр. Юк, берәүгә дә бирмәдем. Күңелем кушмады. Хастаханәдә үлсә, үземне кичерә алмам, дидем. Менә биш елдан артык тәрбиялим мин аны. Кашыктан ашатам, асларын алыштырам, юындырам, – ди Миңлегөл апа.

Пенсиядәге хатын-кызга 45 яшьлек ир-атны каравы җиңел түгел. Җитмәсә, күптән түгел генә үзе дә катлаулы операция кичерде. Хәле авыр булгач, Илдусны вакытлыча хастаханәгә урнаштырып торганнар.

– Безгә ярдәм кулы сузган барлык кешеләргә рәхмәтем чиксез, – ди Миңлегөл апа, күз яшьләрен сөртеп. – Исән чагымда кулымнан килгәнчә тәрбиялим әле мин аны. Караудан бигрәк, аның хокукларын яклау авыррак булды минем өчен, – дип уфтанып та куя.

Илдусның әти-әнисе үлгәннән соң, җиде ай дәвамында пенсиясен ала алмаган. Инвалидның Шәле авылындагы төп нигезе бик тузган. Анда яшәр өчен шартлар юк. 2013 елда Миңлегөл апа инвалид егетнең торак шартларын яхшырту буенча район хакимиятенә документлар җыеп тапшырган булса да, әлегә фатир күренми.

Торак мәсьәләсендә ачыклык кертү өчен, без Питрәч районы Торак фондына мөрәҗәгать иттек. Баксаң, Илдус Мөхәммәтшинны торак шартларын яхшырту буенча 2015 елда ук чиратка бастырган булганнар икән. Тик фатир буласы гына билгесез.

– Закон нигезендә 2005 елга кадәр документларын тапшырып, чиратка басканнар федераль исемлек буенча торак алса, аннан соңгыларга фатирлар социаль найм нигезендә бирелә. Хәзер Мөхәммәтшин чират буенча якынча 46нчы урында. Питрәчтә төзелә торган йортлар берничә категория кешеләргә каралган. Ә алар күп: муниципалитет карамагындагы тузган торактагылар, янгында зыян күргәннәр, сугыш ветераннары, инвалидлар... Инвалидлар өчен генә аерым йорт төзелер дип әйтеп булмый. Торак биргәндә инвалидның хәлен, авыруының ни дәрәҗәдә катлаулы булуын да исәпкә алачаклар. Кызганыч, быел да, киләсе елга да фатир булыр дип вәгъдә итә алмыйбыз, – дип аңлатылар белгечләр.

Вәгъдә ителгәнне биш ел көтәләр

Өметсез шайтан гына, диләрме әле? Редакциябезгә моннан берничә ел элек ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән Шакировлар гаиләсе, ниһаять, фатирлы булды.

Былтыр социаль яклау бүлеге хезмәткәрләре, опека органнары, күп балалы гаиләләрне тикшереп йөргәндә, Яшел Үзән районындагы Норлат авылында яшәүче Шакировлар гаиләсенә дә кергәннәр иде. Фатирда куркынычсызлык таләпләре үтәлми, дип, опека органнары Шакировларның өченче уллары – ике яшьлек Илдарны алырга мәҗбүр булдылар. «ШК» журналистлары исә, берничә мәртәбә суд утырышында катнашып, гаиләне яклап чыкты. Шакировлар даими күзәтү астында булачак дигән шарт белән, баланы гаиләгә кире кайтара алдык. Әлеге вакыйганы даими укучыларыбыз хәтерле торгандыр, бу хакта газетабыз битләрендә дә язылды. Шакировлар редакциябезгә торак шартларын яхшыртуны сорап та мөрәҗәгать иткән иде. Алар Норлат авылының Совхоз урамында урнашкан 20нче күпкатлы йорттагы фатирда теркәлгәннәр. Начар шартларда яшәү авырлашкач, күпләр торактан күченергә тотынган. Ирле-хатынлы икесе дә инвалид Шакировлар да, өченче балалары тугач, түбәдән су агуга, салкынга түзә алмыйча, сеңлесенең фатирында яши башлаган иде.

«ШК» журналистлары ике ел элек бу йортны күреп кайтты. Ул чакта йортның авышкан кирпечләрен, ватык тәрәзәләрен күреп, монда кеше яши аламы икән, дип гаҗәпләнгән идек. Яшел Үзән районы хакимияте: «2011 елда йорт авария хәлендә һәм сүтелергә тиеш дип табылган. 2013-2017 елларга исәпләнгән программа буенча, тузган торакта яшәүчеләрне башка фатирларга күчерү мәсьәләсе хәл ителә», – дип җавап биргән иде «Шәһри Казан»га. Җитәкчелек сүзендә торды. Вәгъдә ителгәнне биш еллап көтәргә туры килсә дә, ниһаять, биредә яшәүчеләргә яңа фатир ачкычлары тапшырылды. Кайбер фатир хуҗаларын гына сөендермәгән бу яңалык, чөнки торакны үз авылларыннан түгел, Түбән Карамалы авылыннан биргәннәр. Шакировлар гаиләсе исә уфтанмый. «Кайда гына булса да, үз торагыбыз, бер бүлмәле булса да, ул зур, якты, уңайлы. Кызганыч, ирем генә бу көннәрне күрә алмады, гүр иясе булды», – дип моңсулана Света Шакирова.

Безгә яхшы юл кирәк

Тукталыштан Залесный бистәсендәге мәдәният йортына бару бер газапка әйләнде. Юл тар, ике яктан койма белән уратып алынган, ике машина кара-каршы очрашса, үтәрлек түгел. Җитмәсә, язын, җәен, көзен пычрак. Җәяүлеләр өчен тротуар да ясамаганнар. Машиналар еш кына пычрак чәчрәтеп уза. Бәлки бу урамга машиналар кермәслек итеп махсус юл билгесе куярга кирәктер. Берсендә бозлавыклы вакытта бер бала, тыкрыктан барганда аягы таеп китеп, чак машина астына кермичалды. Бер әби егылып, пычракка батып беткән иде. Клубка еш кына балалар, пенсионерлар йөри. Берничә метр юлга асфальт салырга әллә ни зур чыгымнар да кирәк түгелдер. Җитәкчелектән Залесный бистәсендә тукталыштан мәдәният йортына илтә торган юлны төзекләндерүне сорап, «Шәһри Казан» газетасы аша мөрәҗәгать итәргә булдык.

Мәдәният йортына йөрүче
әби-бабайлар исеменнән,
Гүзәл ГЫЙБАДУЛЛИНА.

Без бу мәсьәлә уңаеннан Киров һәм Мәскәү районы хакимиятенә мөрәҗәгать иттек. Районның матбугат үзәге җитәкчесе Екатерина Ямбаршева аңлатуынча, Залесный бистәсендә дә, Казанда да ремонт таләп иткән юллар бар. Кызганычка, быелга финанс чыгымнары җитәрлек булмау сәбәпле, бар урында да юлларны төзекләндерү мөмкин түгел. «Әмма укучыларның үтенечен, ягъни Осиновский тыкрыгын ремонтлауны 2018 елга юл төзелешләре программасын формалаштырганда исәпкә алачакбыз», – диде Екатерина Ямбаршева.

Дүрт елга якын эшләп килгән «Яхшы гамәлләр көне» фонды директоры Рөстәм Хәсәнов – Татарстанда гына түгел, Россиядә дә билгеле хәйриячеләрнең берсе. Ул Россиядә беренчеләрдән булып Особенные дети.РФ иганәчелек интернет-кибетен ачты. Церебраль параличлы балаларны махсус җайланмалар, урындыклар белән тәэмин итүне максат иткән масштаблы проект, дәүләттән кала, авыруларга бушлай ярдәм итүче бердәнбер оешма. Хәер, фондның эше моның белән генә чикләнми әле. Аның кысаларында эшләп килгән гаять әһәмиятле башка проектлар, илебездә хәйриячелеккә мөнәсәбәт турында без Рөстәм Хәсәновның үзе белән сөйләштек.

Фотолар: Илдар Мөхәммәтҗанов, kzn.ru

«Хәйриячелек минем өчен – хобби»

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҮРНӘК

– Рөстәм, башка бик күп иҗтимагый оешмалардан сезнең фонд кай ягы белән аерыла?

– Беренчедән, без акча белән турыдан-туры эшләмибез. Алар шунда ук урындыклар ясаучы ширкәткә күчерелә. Икенчедән, закон буенча, хәйрия оешмалары җыелган акчаларның 20 процентын үз ихтыяҗларына куллана ала. Ләкин без бу акчаларның бер тиенен дә файдаланмыйбыз. Өченчедән, үз эшебезгә волонтерлар җәлеп итмибез. Дүртенчедән, без дәүләттән бернинди дә ярдәм алмыйбыз. Бишенчедән, без бер тапкыр гына була торган вакыйгалар белән шөгыльләнмибез. Мондый хәл фонд эшчәнлегендә бер генә тапкыр булды. Ул вакытта без йортлары янган бер гаиләгә ярдәм иттек. Без зур масштабтагы проблемаларны чишәбез.

– Үзенчәлекле балалар өчен җиһаз» проекты – үзегез өчен иң кадерлеседер, дип уйлыйм. Федераль масштабтагы әлеге уникаль проект эшчәнлегендә бүген нинди үзгәрешләр бар?

– Без бу эшне 2013 елда башлаган идек. Шушы вакыт эчендә меңнән артык баланы махсус урындыклы иттек. Бу искиткеч күрсәткеч, моның артында бик зур хезмәт тора. Эшебезнең ни дәрәҗәдә масштаблы булуын чагыштырыр өчен әйтеп күрсәтим: дәүләт Россиянең берничә субъектындагы инвалид баланы шушы кадәр урындык белән бер ел тәэмин итә. Әле бу ярдәмне алыр өчен бик күп документлар җыярга, мең катлы бюрократия юлларын узарга кирәк. Ә вакыт аяусыз – үзенекен эшли. Безнең урындыклар исә, акча күчерүче булган очракта, тиз арада авыру балага бер ай эчендә барып ирешә. Дөрес, кайвакыт бер ел да көтәргә туры килә. Чөнки даими чират бик зур – 300-350 кеше. Кайвакыт, акча җитмәү сәбәпле, гариза кабул итүләрне туктатырга да мәҗбүрбез. Урындыкның сатудагы варианты 40 мең сум тора. Ә безгә аларны «Назаров» ширкәте 10 меңгә эшләп бирә.

– Узган ел ахырында сез бит әле тагын бер җиһазга патент алгансыз дип беләм. Анысы алдагысыннан нәрсә белән аерыла?

– Аларның аермалыклары зур. Без ортопедик урындыкның яткыру һәм бастыру функциясен башкара торган вертикализатор гына патент алдык. Бу бик кыйммәтле җиһаз, кибеттә ул якынча 80 мең тора. Әмма бездә аның бәясе дүрт мәртәбә арзанрак булачак. Әлегә бу төр урындыкны җитештерми торабыз, гаризалар да кабул итмибез.

– Сезнең тагын бер зур проектыгыз – Декабристлар урамының 113нче йортында урнашкан «Хәйрия склады» да бик нәтиҗәле эшләп килә. Гафу итегез, тик үзем өчен бик кызык: кешедән калган киемне кияргә теләүчеләр күпме Казанда?

– Ничек кенә әле! Дүрт ел эчендә әлеге складка ун меңнән артык кеше мөрәҗәгать итте. Бер сезоннан икенчесенә күчеш чорында су буе чират тезелә хәтта. Моңа кадәр 300 квадрат метр мәйданда урнашкан складка кием-салым, азык-төлек, көнкүреш җиһазлары кабул иттек. Тиздән мэрия безгә тагын да зуррак мәйданлы бина бирергә тиеш. Алып килүчеләр дә төрле категория кешеләр. Кемдер әбисенең иске пәлтәсен китерә, ә кемдер ярлыгы да алынмаган 18әр меңлек берничә кием-салым алып калдырып китә. Казанлылар гына түгел, бөтен Татарстаннан киләләр. Шунысы да мөһим: безгә урамнан теләсә кем керереп, күпме тели, шулкадәр кием-салым яки башка кирәк-ярак алып чыгып китә алмый. Башта социаль хезмәтләрдән юллама алырга кирәк. Һәрнәрсәнең үз тәртибе бар. Кешеләр үзләреннән арткан әйберләрен якшәмбедән кала һәр көн сәгать 9.00дан 18.00гә кадәр китерә ала. Ә мохтаҗларга 9.00-13.00 сәгатьләрдә бирелә. Һәр киемгә – баллар, ә кеше саен билгеле бер лимит билгеләнә. Кием сайлап алу өчен исә бер сәгать вакыт бирелә, ягъни чит кеше киемнәренә дә ихтирам белән һәм аңлы рәвештә карарга тырыштык. Болардан кала, тагын бер проект турында әйтәсе килә. Авыру балаларны тәрбияләүче аз керемле гаиләләрне һәм мөмкинлекләре чикле кешеләрне Казан буенча бушлай социаль такси йөртә. Кая да булса бару өчен, өч көн кала, (843) 245-48-02, +7 937 615-48-02 телефон номерларына шалтыратып, таксига заказ бирергә кирәк.

– Фондка акча күчерүчеләр арасында танылган шәхесләр дә бармы?

– Байлар да, урта хәлләр дә, сәхнә йолдызлары да очрый. Хәтта төрмәдә утыручыларның да акча күчергәне бар. Катнаш төрдәге кара-каршы көрәш буенча Россия чемпионаты финалы кысаларында, Федор Емельяненконың култамгалы перчаткасы аукционда ике миллион сумга киткән иде. Аннан соң ул акчалар безнең фондка күчерелде. Җырчылар арасында милләттәшебез Максим, «Корни» төркеме солисты Саша Асташенокны, шулай ук хәзерге вакытта Франциядә яшәүче гандбол буенча дөнья чемпионы Константин Игропуло турында да әйтергә мөмкин. Бер үк төрле яхшылыкны төрле-төрле кеше эшләгәч, монда кешелеклелек сыйфатлары турында уйларга җирлек җитәрлектер дип уйлыйм.

– Сез үзегез хисчән кешеме?

– Ничек кенә әле! Фондка килгән хатларның яртысын укымыйм, чөнки булдыра алмыйм. Урындыкларны тапшырырга да үзем бик сирәк барам, чөнки мондый очрашуларны бик авыр кичерәм. Миңа оештыру эшләре күпкә җиңелрәк бирелә.

– Башкалар кайгысына битараф калмыйча, чит кеше мәнфәгатьләрен үзенекеннән өстен куеп, ихластан кайгырып, янып йөрүче кешеләр бик аз. Шуңа күрә: «Сиңа бу эш нигә кирәк?» – дип сораучылар да очрыйдыр.

– Дөнья кара һәм ак төсләрдән гыйбарәт. Әгәр сез нинди дә булса яхшылык эшләп, шуңа ак төс өстәсәгез, яхшылык күбрәк була, дип аңлатам андыйларга. Россиядә 140 кешегә бер церебраль параличлы бала туры килә. Димәк, әлеге балаларның барысын да урындык белән тәэмин итәр өчен һәр кешедән 80 сум акча җыю да җитә. Әгәр мэрия белән берлектә башлаган эшне ахырга кадәр җиткерсәк, Казан бөтен кешесенең дә кияргә киеме, ашарга ризыгы булган Россиядә беренче шәһәр булачак. Шәп бит инде! Өч-дүрт ел элек Россиядәге иҗтимагый оешмаларның саны 3000 тирәсе иде. Чынлап торып эшләүчеләр дә күп, әмма аларның күбесе нәрсә, ни өчен эшләгәннәрен аңлап бетерми: эшләре системага салынмаган, структуралары юк. Хәйрия эшендә хисләр белән генә идарә итәргә ярамый. Без хисап тотабыз, әмма, гадәттә, кешеләр җибәргән акчаларының нәрсә өчен тотылганлыгы белән кызыксынмый. Кешеләр бу адымнарын акыл белән аңлап эшләсеннәр иде. Безгә шунысы бик мөһим. Без акча белән турыдан-туры эшләмибез дидем. Кайвакыт: «Ашарга алыр өчен акча бирегез әле», – дип киләләр. Андыйларга акча түгел, ризык бирәбез, дигәч, үзебезнең адреска әллә нинди сүзләр ишетәбез. Кызганычка, андыйлар бик күп. Хәйрия белән акча эшләүчеләр дә күп. Иртәме-соңмы, без аларның эзенә барыбер төшәчәкбез әле. Бу тармакта төрмәгә утырырлык җитди сәбәпләр бик күп. Татарстанда андыйлар азрак, әлбәттә. Бездә халык кешелеклерәк, ә Россия буенча карасак, хәйриячелек тармагында караклык авыруы бик тирәнгә киткән. Моны тиз арада законга үзгәрешләр кертеп, «дәваларга» кирәк. Әлегә минем кулда моңа каршы инструмент юк, әмма, иртәме-соңмы, аның булачагында шигем юк, чөнки хәйриячелек дигән булып, бик күп акчалар үзләштерелә. Иганәчелек астына коточкыч зур бомба салынган. Башка юнәлештәге, тармактагы караклыкны аңларга була әле, ә менә хәйрия акчаларын урлауны берничек тә гафу итәргә ярамый.

– Ничек уйлыйсыз, ә гади халыкның иганәчелеккә карата караш-мөнәсәбәте үзгәрдеме?

– Юк, берни дә үзгәрмәде. Кешеләр ничек сукырларча ышанганнар, шулай дәвам итәләр. Хәйрия өлкәсе үзе елдан-ел үсә анысы. Әмма бу, кызганычка, кешеләр яхшырак, кешелеклерәк була барганга түгел, ә әлеге өлкәне һөнәр иткән кешеләрнең артуына бәйле. Россиядәге хәйрия фондларының күбесе җыелган акчалардан алынган процентлар хисабына яши. Ә бу инде эшмәкәрлек дигән сүз. Минем үземнең «Реставратор» төзелеш компаниям бар. Әмма аның хәйриячелеккә бернинди дә катнашы юк. Дөрес, анда мин акча эшлим, ә фондта түздырам (*Көлә.* – **З.С**.). Узган ел Казанда сакланып калган иң иске йортларның берсе – Иван Михляев йортын (XVII гасыр) яңадан сафка бастырдык. Әгәр мөмкинлегем булса, тулысы белән үземне хәйриячелеккә багышлар идем, әмма гаиләне, өч баламны да туендырырга кирәк бит. Шуңа күрә эшмәкәрлек – минем төп эшем, ә хәйриячелек – хобби.

«ШК» КУНАКТА

Автор фотосы

«Әле кичә генә биләүдә иделәр»

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА,
Казан – Әлмәт – Казан

– Аягыңа уралып, тешсез авызы белән: «Әннә, мәммәм», – дип кабатлап торган, ишектән үк: «Әни, «бишле» алдым», – дип сөенеп кайтып кергән, ишегалдында балта-чүкеч тотып, әтисе артыннан бер дә калмый ияреп йөри торган ул-кызларың булмаса, нинди гаилә ди инде ул. Олылары үсеп житеп кул астына керә башлагач, телевизордан сабый бала күргән саен, безнең дә тупырдап торган бала сөясебез килә башлый. Башта өчесе янына дүртенчесе дә сыяр, аннары булган булган бер йодрык кебек булсыннар инде дия-дия, бишенче балабызны да алып кайттык. Күптән түгел генә безгә «Татнефть» микроавтобус бүләк итте, – дип каршы алды мине Әлмәттә яшәүче күп бала анасы Альмирә.

Әлмәт якларына баргач, анда яшәүче Альмирә һәм Кәрим Баһаветдиновлар өенә дә сугылып чыктык. Өйдә кызлар гына иде. Йорт хуҗасы Назыйм эштә, ә олы уллары Сирень Әлмәт дәүләт нефть институтында укуда, дүрт яшьлек Альберт балалар бакчасында. Диана белән Чулпан мәктәптән кайтканнар, төпчекләре Фәниягә ун гына ай, апалары аны кулларыннан да төшерми, әле берсе, әле икенчесе ике битеннән үбеп кенә торалар.

– Балалар белән озаклап декрет ялында утырганым да юк, олылары кечкенәләрен миннән бер дә ким карамый. Кайчан ашатасын да, кайчан йоклатасын да белеп торалар. Әни, дус кызларың белән очрашып, ял итеп кайт дип, мине утырмага да чыгарып җибәрәләр, – дип көлә Альмирә ханым. – Өч бала житкән, нәрсәгә тагын бала алып кайтасың, дип әйтүчеләр дә булды. Ә әнием, тап, кызым, һәр бала үз бәхете, үз ризыгы белән туа, дип әйтә килде. Әле кичә генә биләүдә яталар иде, кай арада үсеп тә җиттеләр соң, дип, үзебез дә гаҗәпләнеп куябыз. Өйдәге эшләрнең күбесен Диана эшли, Сирень ишегалдында, хуҗалык эшләрендә әтисенең төп ярдәмчесе. Һәрберсенең үз холкы. Диана миңа охшаган, ул да милициядә эшләргә хыяллана. Сирень әтисе кебек тыныч холыклы.

– Ә мин – әтинең яраткан кызы, – дип сүзгә кушыла сигез яшьлек Чулпан.

– Чулпан апасы белән абыйсыннан соң шактый вакыт үткәч туды, кечкенәләре туганчы, ул төпчегебез булды. Ә төпчек бала, үзегез беләсез, иркә була, – ди Альмирә, елмаеп.

Назыйм белән Альмирәнең өйләнешкәннәренә 20 ел булган. Альмирә Чаллыда милициядә балигъ булмаганнар белән эшләү бүлегендә хезмәт куя, Назыйм дуслары янына кунакка килгән була, шунда таныша да алар. Озакка сузмый гына өйләнешеп тә куялар. Яңа йорт җиткезәләр. Назыйм 30 елдан артык инде «Елховнефть»тә слесарь булып эшли. «Татнефть» Яңа елга Баһаветдиновлар гаиләсенә җиде урынлы «Соболь» микроавтобусы бүләк иткән.

– Җиңел машинабыз бар иде, әмма аңа барыбыз да сыя алмый идек. Гаилә белән җыелышып беркая да бара алганыбыз булмады. Әнием Оренбург өлкәсендә берүзе генә яши. Аның янына да бергәләшеп барган юк. Хәзер инде җәйгә җыелышып аның янына барырга уйлыйбыз, диңгезгә дә бара алачакбыз. Микроавтобус безгә чын мәгънәсендә зур бүләк булды. Менә бу елларда балалар Әлмәт театрына бара, билетларны бушка шулай ук «Татнефть» биргән. Алар тарафыннан ярдәмне гел тоеп яшибез, бәйрәмнәрдә дә игътибарсыз калдырмыйлар. Балаларны лагерьга урнаштыру мәсьәләсен дә хәл итәләр, – ди Альмирә.

Баһаветдиновларның бакчаларында ике теплица тора, яшелчәләрен дә, бәрәңгесен дә күп итеп утырталар.

– Бакчада барыбыз да эшләргә ярата. Балаларга да, тырышкан кеше ач калмас, дип гел әйтеп торабыз. Булдыклы кеше беркайчан да югалып калмый, – ди биш бала анасы Альмирә.

ЗАМАН ЧИРЕ

Сак булыгыз: СЕЛФИ

Соңгы вакытларда чәчәк кибетләре ялгыз ханымнарга селфи өчен прокатка 101 роза гөлләмәсе алу һәм «Мерседес» машинасында фотога төшү мөмкинлегенә кадәр тудыра. Әлеге бизнес аеруча Мәскәүдә күптәннән уңышлы эшләп килә икән. Анда хәтта фотога кочаклашып төшү өчен егет тә чакыртырга була, диләр.

Селфи... Кайчандыр «Ну, погоди!» мультфильмындагы үз-үзен фотога төшергән бүрене күреп, рәхәтләнеп көлә идек. Ә хәзер бу бер дә көлке түгел. Хәтта аны психик авыруга кертәләр. Сүз шоу-бизнес йолдызлары хакында түгел, ә безнең балалар турында. Сүз дә юк, артистларга әлеге ысул – имидж, бюджетлы пиар һәм реклама.

Җәмәгатьчелектә, психологларда, укытучыларда һәм әти-әниләрдә селфи курку тудыра башлады. Әлеге чир кемгә яный? Ничек дәваланырга? Психолог **Регина Ибраһимова** белән нәкъ шушы темага әңгәмә кордык.

– Ни өчен яшьләр селфи белән мавыга? Бу эшсезлектәнме, үз-үзләрен артык яратудан чыккан шөгыльме?

– Бу агым балалар белән яшьләрдә генә түгел, өлкән буын вәкилләрендә дә шактый кызыксыну уятты. Селфи социаль челтәргә куяр өчен эшләнә. Ә анда синең үз аудиторияң һәм алар синең хәбәрләреңне күзәтеп тора. Заманында, мәсәлән, безнең әниләр, кайнар яңалыкларын хәбәр итәр өчен, телефоннан ахирәтләренә шалтыратканнар, бүлешкәннәр. Ә хәзер мода башкача. Селфи куеп, виртуаль дөньяда үзеңчә бер ярыш башлана. Дусларың синә «лайк»лар куя. Менә шуларның саны аз булу баланы депрессиягә илтә дә. Шуңа да бүген күпләр үз-үзенә кул салуга әзер халдә.

Хәтерлисездер, күп лайклар җыям дип, бер бала көн дә иртән уяну белән идеаль селфи эшлим дип тырышкан. Бу эшкә җитди алынып, хәтта мәктәпкә йөрүеннән дә туктаган. Әмма селфи теләгәнчә чыкмаган. Малай, дарулар ашап, үз-үзен агулап үтермәкче була, әмма әнисе аны коткарып кала. Мондый мисаллар бихисап.

Өстәвенә, экстремаль шартларда фотога төшәм дип дөнья куйганнар да бик күп. Россиядә селфины биек йорт түбәләрендә, кыя, текә яр башында төшкәндә үлгәннәрнең саны берничә йөз кеше тәшкил итә. Шуңа да селфи хәзер куркыныч шөгыль дип санала. Фото ясау «кем-кемне уздыра» принцибына корылгач, гомеренә куркыныч янаганын уйлап та тормыйлар. Безнең психология бит шундый: берәү мактанса, без аны уздырырга тиеш.

Үз фотосын урнаштыручыларга лайк бары тик вакытлыча җиңеллек бирә. Селфи ясаучының лайк «доза»сы һәрвакыт артып тора: киләсе тапкыр «миңа ошый» төймәсенә тагы да күбрәк кеше басарга тиеш. Һәм моның ахыры булмаячак. Бу чир түгелмени? Фотокамера колына әйләнгән якыннарыбызны саклап калырга ашыгыйк.

– Селфи чире кемгә яный? Нинди холыклы кешеләр моның белән мавыга?

– Үз-үзенә түбән бәя бирүчеләр. «Мин кирәгенчә яхшы түгел», – дип фикерләүчеләр моның белән шөгыльләнә дә. Бу кешегә игътибар җитми, аның популяр буласы килә. Ә бит балалар гына түгел, өлкәннәр өчен дә тирә-яктагыларның алар турында нинди фикер йөртүе, нәрсә уйлавы мөһим. Менә шул уйлар хроник депрессиягә илтә дә.

Ә икенче берәүләр шул фотоларны карап утыра. Ягъни аларда кеше тормышы белән кызыксыну уяна. Анысы да бер авыру.

– Берүнкәсез шөгыль балалар өчен хәвефле булып китмәсен өчен, әти-әниләргә нинди киңәш бирерсез?

– Беренче очракта әти-әни үзенең баласына нинди мөнәсәбәттә икәненә игътибар итәргә тиеш. Сезнең аны яратуыгызны, аңа карата игътибарлы булуыгызны ул аңлыймы? Аның тышкы кыяфәте, холкы, кыланышлары турында аңа нәрсә әйтәсез? Баланың башка әйберләргә бәйлелеге юкмы? Гаджетлар, виртуаль уеннарга бәйле, качып тәмәке тарта, эчә... Чөнки бу барлык бәйлелекләрнең дә килеп чыгу табигате бер: мәхәббәт һәм ихтирам җитмәүдән. Әгәр дә гаиләдә аны тиешенчә яратмасалар, ул үзенә башка җирдән танылу эзли башлый.

«Син минем тормышымда бар һәм шуның өчен мин сине яратам да» дигәнне гаилә әгъзалары бер-берсенә сүз, кылган гамәлләре белән аңлатырга тиеш. Бернинди дә шартларга корылмаган мәхәббәт булган урында бар да яхшы була. Бала белән һәрчак позитив элементта булырга кирәк. «Миңа ярдәм иткәнең өчен рәхмәт», «Телефоннан сөйләшкәндә комачауламаганың өчен рәхмәт», «Син шундый игътибарлы һәм кайгыртучан» кебек җылы сүзләрне җөлләмәскә тырышыгыз.

Ә селфи чиренең өч этабы бар. Менә соңгысы – иң куркынычы. Чөнки анда чын мәгънәсендә бәйлелек туа, кеше селфи ясамый торса, күңел төшенкелегенә бирелә, тормыш ямен югалта. Аның белән мавыгып, мөһим эшләрен бөтенләй оныта: уку артта кала, гаиләсе белән вакыт уздырмый... Көн дәвамында балагыз алты яки аннан күбрәк селфи ясый икән, димәк, уйланырга вакыт. Кичекмәстән тормыш кыйммәтләрен үзгәртегез. Селфига алмашка күңел рәхәтлеге бирә торган башка шөгыль уйлап табыгыз.

Азалия ИСМӘГЫЙЛЕВА.

КИҢӘШ САНДЫГЫ

АШ БУЛСЫН!

Туклыклы салат

2-3 помидор, 500 гр тавык түше, 150 гр каты сыр, бер банка консервланган кызыл фасоль, яшел салат, сухари, майонез.

Помидор белән салатны вак итеп турыйбыз. Сырны угычтан уабыз. Тавык түшен вак итеп турап кыздырабыз. Аларга сохари белән фасоль, майонез кушып болгатабыз.

БАКЧАЧЫГА

✓ Кәбестә күбәләгеннән котылу өчен, кайбер бакчачылар валерьян даруын кулланa. Өч литр суга бер шешә валерьян даруы һәм бер аш кашыгы сыек сабын салырга һәм шуны зарарлы бөҗәкләр ияләшкән кәбестәләргә сибәргә кирәк. Саклауга куелаcы кәбестәләрне түтәлдән алырга бер ай кала, нашатырь спирты сиптерәләр. Моның өчен биш литр суга бер шешә нашатырь спирты (40 мл) һәм ике аш кашыгы сыек сабын салып болгатыра.

✓ Чөгендер тар түтәлдә яхшырак үсә.

✓ Укропны, кишер, чөгендерне кояш төшә торган урынга утыртыгыз.

✓ Кишер, чөгендерне алдагы елда кәбестә, борчак, кыяр, суган утырткан җиргә утыртыгыз.

✓ Кукуруз, борчак, кабакны бергә янәшә утыртыгыз.

✓ Суган белән кишер дә үзара килешә белә.

✓ Помидор белән базилик та үзара дус.

✓ Баклажан янәшәсенә утыртылган фасоль аны колорадо коңгызыннан саклый.

ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ

Күзләр өчен гимнастика



ФАЙДАЛЫ



Тәмле дару

- Халык табиблары фикеренчә, инжирны аспирин урынына да кулланырга була, чөнки аңардагы эфир майлары кан составын көйли. Моның өчен ай буена һәр көн берәр инжир ашарга кирәк. Бер айдан тагын кабатларга.
- Инжир баш мие эшчәнлеген яхшырта.
- Ангина, бронхит вакытында, авызда инфекция булганда, температура күтәрелгәндә бер аш кашыгы вак итеп туралган инжир өстенә ике стакан кайнар су салабыз. Аны сүрән утта ун минут пешерәбез. Суынгач, сөзеп, көненә дүрт тапкыр эчәбез. Әлеге рецептны цистит, пиелонефрит булганда да файдаланырга була.
- Стресс кичергәндә, арыганда бер стакан җылы сөткә ваклап туралган инжир салып эчәбез.
- Инжир иммунитетны да ныгыта. Моның өчен аңардан салат ясап ашарга киңәш итәбез. Әлеге салатны һәркем яратып ашаячак. Безгә 300 гр инжир, 150 гр кара җимеш, 2,5 аш кашыгы миндаль, 1 стакан кефир, әфлисун кабыгы кирәк була. Кара җимеш белән инжирны нечкә итеп турыйбыз. Чикләвекне блендерда изәбез. Әфлисун кабыгын ваклап турыйбыз, кефир кушып, барысын бергә болгатабыз. Шикәр комы салырга кирәкми.

ХУҖАБИКӘГӘ

Гөлләрегез мул итеп чәчәктә утырсын дисәгез, түбәндәге киңәшебезне истә тотыгыз.

Бер литр җылы суга 10 гр чүпрә һәм бер аш кашыгы шикәр комы салып болгатабыз. Ике сәгать тонаткач, әлеге эремәгә су кушабыз (1:5). Шуны көзен һәм кышын айга бер мәртәбә, яз һәм җәйдә ун көнгә бер тапкыр сибәбез. Чүпрәдәге фитогормоннар, В төркеме витаминнары һәм ауксиннар гөлләр өчен менә дигән ашлама булып тора.

Гап-гади киңәш

Сынап кара

Арахисны (җир борчагы) безнең җирлектә дә үстереп була икән. Бу эшкә март ахырында ук тотынырга кирәк. Арахис чикләвеген кыяр орлыгы кебек дымлы марляга төреп куясың. Клеверны хәтерләткән үрентесе икенче көнне үк күренә башлый Аннары аларны туфрак тутырылган савытларга утыртып чыгасың. Май ахырында инде аларны ачык туфракка чыгарып утыртасың, өстен каплыйсың. Җәй буе су сибеп, төбен бәрәңге кебек өясең. Сентябрь аенда казып алырга да була.

БЕЛЕП ТОР

Лимон мае косметологиядә генә түгел, көнкүрештә дә киң кулланыла. Даруханәдә сатыла торган әлеге май һәркемнең өендә булырга тиеш.

- Сөялләрдән котылу өчен һәр көн иртән һәм кичен шул урынга лимон мае сөртегез.
- Лимон мае бит тиресен яхшырта, төсен үзгәртә.
- Иренгә герпес чыккан очракта да лимон мае сөртергә кирәк.
- Җиләк-җимешләр озаграк саклансын өчен, савытка су салып, аңа ике-өч тамчы лимон мае тамызыгыз һәм шул суда җиләк-җимешне юып алыгыз.
- Өйдә ят ис булганда, диффузор ярдәмендә лимон мае сиптереп чыгыгыз.
- Кулны юарга мөмкинлек булмаганда, дезинфекция өчен, учка берничә лимон мае салып ышкыгыз.

Алтын сүзләр

- Һәр көн нәрсә дә булса эшләгез.
- Планлаштырган әйберегез ният кенә булып калмасын.
- Белемегезне, тәҗрибәгезне арттыру өстендә эшләгез.
- Проблема турында түгел, аны хәл итү юллары турында уйлагыз.
- Эшләргә җайлы булган әйберне түгел, мөһим дип санаганын эшләгез.
- Һәр эшне ахырына кадәр җиткерегез.
- Вакытыгызны яратыгыз, аны юкка әрәм итмәгез.
- Акчаны дөрес сарыф итәргә өйрәнегез.
- Буш кеше белән аралашканчы, яхшы китап белән «сөйләшегез».
- Ял да итә белегез.

МӘЛЕНӘ–ӘМӘЛЕ

Иске велосипед тәгәрмәченнән яки тәгәрмәч тугымыннан (обод) кыяр, борчак өчен вертикаль түтәл ясарга була.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА әзерләде.

Инвалид арбасында – сәяхәткә

Башкортстанның Белокатай районы егете Илдар Галиәкбәров, авылда эш булмагач, үзен башкалада сынап карамакчы була. Уфага күченә, тиз арада эшен дә таба. Алтын таулар вәгъдә итмәсәләр дә, эше үзенә бик ошый. Аралашучан булгач, дуслары да күп. Буш вакытын алар белән уздыра.

– Юл һәлакәтенә иртән эшкә барганда юлыктым, юл чыкканда, машина бәрде. Кем бәргәндер, көрттә күпме ятканмындыр – бер нәрсә дә хәтерләмим. Хастаханәдә уяндым: аяк-кулларым мумиянеке кебек кара төстә һәм кипкән иде. Мине көрт арасыннан бик соң гына эзләп тапканнар, аңсыз ятып, аяк-кулларымны өшеткәнмен, – ди ул.

Башта табиблар Илдарга аяк табанын гына ампутацияләргә тиеш булган, ә уянганда – тезенә кадәр аяклары киселгән була аның... Өстәвенә кул бармаклары да юк.

– Табиблар миңа игътибарын җәлләмәде, яхшы карадылар. Палатадагы егетләр дә күңелле кешеләр булып чыкты. «Хәзер носки аласың булмый, аягыңа гөмбә авыруы «ябышмаячак», – дип шаярттылар. Алар миңа күңел төшенкелегенә бирелмәскә ярдәм итте. Нишлисең, күрәчәгең булса, аннан берничек тә качып булмый.

Әти-әнисе инде күптән исән түгел. Дәваханәдән аны апасы үзенә алып кайта. Тик анда Илдар үзен уңайсыз хис итә. Башта инвалид коляскасы да булмый, икенче катта яшәү дә кыенлыклар тудыра. Һәрвакыт фатирда бикләнеп яту Илдарга килешмәгәнен күреп, апасы: «Бәлки Уфага интернатка урнаштырыргадыр? Кем белә, бәлки анда үз тиңеңне дә очратырсың», – ди. Илдарга ошый бу тәкъдим.

Уфага килүгә үк, егет үз теләге белән аш-су остасына ярдәм итә. Аңа да берүзенә җитешүе кыен, 50 инвалидка таратып бетергәнче, ашы суынып бетә. Ә Илдар белән бу эш күпкә тизрәк. Ярдәмчел Илдарга пешекче Светлана шундук гашыйк була.

Егеткә интернатта бер дә күңелсез булмый, буш вакытын файдалы итеп уздыра. Спорт белән шөгыльләнә башлый, иртә-кич тренажер залында була. Кулына махсус перчаткалар киеп, интернаттагы җиһазны, коляскаларны ремонтлый. Шәһәр урамнарына да чыгып тренировкалар башлый. Баштагы вакытларда коляска белән берничә йөз метр үтүгә арыса, тәмәке тартуын ташлагач, чакрымнар саны да арта. Марафоннарда катнаша башлавы аңа тагы да стимул бирә. Уфада җәй көне уза торган 1000 велосипед көнендә Илдар да катнаша. Әйтергә кирәк, катнашучылар арасында ул – бердәнбер инвалид.

Иң элек Уфа буйлап йөрсә, тиздән Башкортстан районнары буйлап экскурсиягә чыга. Инвалид коляскасында. Күз алдына китерегез инде! Кайчак машинада барганда да: «Кайчан барып җитәбез инде?» – дип сабырсызланган чаклар була. Ә монда сәгатенә 10-15 чакрым үтә торган инвалид коляскасы. Өстәвенә ул барсын өчен үзеңә көч түгәсе.

Озакламый Илдар эретеп ябыштыручы дуслары белән бергә велоколяска ясый. Велосипед механизмын инвалид коляскасына көйли. Яңа төр техникада йөрүе күпкә җайлырак була. Педаль белән эш итү кәлне дә әзрәк ала. Велосипед әзер булгач, Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан Севастопольгә кораблар парады карарга кузгала. 2,5 мең чакрымны үз транспортында үтә.

– Сәяхәт 23 көн дәвам итте. Иртәнге биштә чыгып, көненә йөз чакрымнан артыграк юл үтә идем. Иң авыры – таулы җирләр. Үргә менү күп вакытны алды. Самарадан соң тигезлек башланды һәм кыенлыклар булмады. Көнәнә иң күп ара Краснодар краенда үтелде, чөнки кунакханәләрдә буш урыннар юк, ә саф һавада кунып калырга батырчылык итмәдем: еланнар күп, бүреләрнең дә борчуы бар... Әмма дальнобойщиклар һәрвакыт ярдәмгә килде. Рация аша бер-берсенә хәбәр итеп, миңа юл биреп бардылар. Алар ярдәме белән, һәрвакыт такыр юлдан бардым.

Илдар бүген Иглин районы үзәгендә хатыны Светлана белән матур итеп дөнья көтә. Гаилә башлыгының планнары зурдан. 17 апрель көнне ул Уфадан киләсе сәяхәтенә – Казахстан башкаласы Астанага кузгалачак. 10-11 көндә барып җитәргә ниятли. Җәй җиткәч, күпкә җаваплырак эшләр көтә. Быел ул йорт сала башларга ниятли. Былтыр хөкүмәт аңа җиде сутый җир бүлеп бирә. Әмма бер пенсиясенә генә өмет итеп ятмый, төзелеш күп акча таләп итәчәген аңлый. Шуңа күрә әлегә ул кибет янында газета таратучы булып эшли. Эше үзенә ошый, район халкы да аны ихтирам итә.

– Авариягә юлыкмаган булсам, бүген нәрсә белән шөгыльләнер идем икән? Мөгаен, эчүемне, тартуымны дәвам иткән булыр идем. Хәзер тормышка башкача карыйм. Ни булуына карамастан, оптимист булып калам. Күңел төшенкелегенә бирелгән инвалидларны да саздан чыгарырга тырышам. Аракы эчеп, проблемаларның хәл ителмәгәнен аңлатам. Күпләрнең мәдәни чараларда да катнашырга теләге юк. Бүгенге көндә Иглин районында яшәсәм дә, Уфада узган чараларны калдырмаска тырышам. Әйе, башта сәламәт кешеләр арасында йөрүе оялдыра иде. Ә соңыннан үз-үземнән оялмаска өйрәндем. Минем өчен бер кыенлык та юк. Ә юк, бар икән. Өйдә тик ятуы. Шуннан да кыены юк.

Азалия ИСМӘГЫЙЛЕВА.

СОРАУ-ҖАВАП

Мин китапханәче булып эшлим. Эш стажым – 30 ел. Авыл хуҗалыгы өлкәсендә исәпкә алуда катнашкан өчен, миңа Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең ведомство билгесе тапшырылды. Бу миңа «Хезмәт ветераны» исемен алырга мөмкинлек бирәме?

Гөлсинә Животникова,
Балтач районы, Чепья авылы.

Татарстанның Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хезмәткәрләре аңлатуынча, закон нигезендә, Россия Федерациясеннән ведомстволы яки дәүләт бүләге алган кешеләрнең әлеге исемгә хокуклары бар. «Хезмәт ветераны» исеменә лаек булыр өчен тагын бер шарт – 20-25 ел эш стажы. Кеше барлык кирәкле документларны җыеп, теркәлү урыны буенча социаль яклау бүлегенә мөрәҗәгать итә ала. 2016 елның 1 июленнән законга кергән үзгәрешләр буенча, әлеге федераль дәрәҗәдәге бүләк хезмәткәрнең үз тармагы буенча алынган булырга тиеш. Сезнең очракта китапханәче буларак, Россия Мәдәният министрлыгыннан бирелгән исем генә кабул ителә. Мәдәният министрлыгы карары белән, бу өлкәдә «Хезмәт ветераны» исемен алырга бары Россия Мәдәният министрлыгыннан бирелгән «Почет грамотасы» гына хокук бирә.

Пенсиягә узган ел чыктым. Эш стажым 29 елдан артык. Тик Пенсия фондында бары 17 ел гына дип исәпләделәр. Бу дөресме?

Мөхәмәтдин Әнвәров,
Казан.

Вахитов районы пенсия бүлеге хезмәткәрләре аңлатуынча, сезнең чынлап та картлык буенча пенсиягез билгеләнү көненә исәпләнгән иминият стажыгыз – 29 ел. Бу стаж сезгә пенсиягә чыгу мөмкинлеге бирә. Яңа кагыйдәләр нигезендә, 2016 елдан пенсиягә чыгу өчен кимендә алты ел стаж таләп ителә. Ә пенсияне билгеләр өчен 2002 елның 1 гыйнварына кадәрге гомуми стаж һәм иминият кертемнәре исәпкә алына. Шул рәвешле пенсияне билгеләгәндә, сезнең 17 ел эш стажыгыз гына исәпкә алынган. Ягъни, 2002 елдан соңгы эш стажыгыз пенсия күләменә йогынты ясамый. 2002 елдан соңгы пенсия бары иминият кертемнәреннән чыгып кына исәпләнә. Әлеге кертемнәр кешенең эш урыныннан Пенсия фондына күчерелеп бара. Пенсия турындагы закон нигезендә, 2002 елдан пенсия нәкъ менә хезмәт хакына бәйле булып чыга. Хезмәт хакы зуррак икән – пенсиягезнең суммасы да күбрәк булачак.

Без Шуртыгин урамында яшибез. Балабызны якындагы мәктәпкә – Инженерлар лицеена беренче сыйныфка укырга бирергә теләгән идек тә, кабул итмәделәр. Уку түләүле дип аңлаталар. Безгә нишләргә?

Кәримовлар гаиләсе,
Казан.

Совет районы Мәгариф бүлеге җитәкчесе **Венера Нуреева** монда ниндидер аңлашылмаучанлык кына килеп чыккандыр дигән фикердә.

– Инженерлар лицеенда уку түләүле түгел. Анда бары дәресләрдән соң, укучыларга түләүле өстәмә хезмәтләр тәкъдим ителә. Территориаль бүленеш буенча Шуртыгин урамында яшәүчеләр чынлап та Инженерлар лицеена карый. Тик әгәр ата-ананы бу белем бирү учреждениесендәге шартлар канәгатьләндерми икән, ул башка мәктәп тә сайлый ала. Киләсе уку елында XXI гасыр торак комплексында яңа мәктәп сафка басар дип уйлыйбыз. Теләгән балалар анда да укырга килә ала. Шулай ук Шуртыгин урамында яшәүчеләрнең 126нчы мәктәптә белем алу мөмкинлеге дә бар. Ничек кенә булмасын, 1 сентябрьгә бер генә бала да мәктәпсез калмаячак, – ди Венера Нуреева.

Ана капиталын балага ничә яшь тулгач файдаланырга ярый?

Хәмидуллиннар гаиләсе,
Казан.

Вахитов районы пенсия бүлеге хезмәткәрләре аңлатуынча, гомуми кагыйдәләр буенча, балага өч яшь тулганнан соң гына ана капиталын файдаланырга була. Дөрес, торак шартларын яхшырту максатларында, капитал фатир өчен алынган кредитны капларга файдаланылса, бала туугa ук акчаларны кулланырга була.

Кызыксындырган сорауларыгызны редакциягә (843)562-50-03 телефоны аша юллый аласыз.

САКАЛЛЫ КЕШЕ ЯЗМАЛАРЫ

Байлык культы

Матди байлыкны күз уңында тотып әйтелә торган «Акыллы булгач, ник бай түгелсең?!» дигәнрәк бер тәгъбир бар. Бу татар сүзе түгел. Татарда акыллыны кимсетү, ахмакны данлау омтылышы юк. Башка бик күп нәрсәләр кебек үк, урыс аша кергәндер инде. Ләкин ничек кенә булмасын, бу сүз бик тәвәккәл яңгырый, игътибарны яулый һәм дөреслек кебек тоела. Чынында ул шыр ялган, дөреслеккә якын да килми.

Марат КӘБИРОВ

Бай булу акыллы булуны аңлатмый. Шыр тиле кеше дә байлыкка ирешергә мөмкин. Бу очракта мин фамилияләр атап, мисаллар китереп тормыйм. Теләсәгез, сез аны үзегез дә бик күп таба аласыз.

Бай булу көчле шәхес булуны да аңлатмый. Дөрес, байлыкка ирешүчеләр арасында көчле кешеләр бик күп, ләкин бу төп шарт түгел – көчле кешеләр ярлылар, аеруча урта хәллеләр арасында тагы да күбрәк.

Бай булу кешелекле, изге күңелле булуны да аңлатмый. Әлбәттә, фәләнешәр миллиард акчасын мохтаҗлар өчен тотучы миллиардерлар да бар. Ләкин бу шәфкатьле кеше генә бай була ала дигән сүз түгел.

Бай булу сәламәт булуны да аңлатмый.

Чибәр булуны да...

Гомумән, бай булу бары тик кешенең бай булуын гына аңлата, әлеге мизгелдә аның мөлкәт күләме зур икәнен генә билгели, ул кешегә өстәмә сыйфатлар бирми. Ул хәтта әлеге мизгелдә бай булган кешенең иртәгә дә бай булачагын да белдерми.

Ләкин...

Ләкин дөньяга мещан күзләре белән карый торган сантыйрак бер төркем бар. Бу – тотанаклы төркем түгел, заманга, яшәү рәвешенә, пропаганда эшчәнлегенә карап үзгәрә торган төркем. Үз зурлыгы, үз авырлыгы, үз йөзе, үз кыйбласы булмаган төркем инде шунда. Менә шушы беркатлырак бәндәләр күзенә бай кеше акыллы да, көчле дә, шәфкатьле дә, сәламәт тә, чибәр дә булып күренә.

Бай булу файдалы булуны да аңлатмый. Ләкин әлеге беркатлы бәндәләр, берәр файдасы тияр әле дигән өмет белән, теге байның бер алдына, бер артына чыгып өлтерәп тора. Моның алдында ялагайлану дәрте белән үзләренә гел яхшылык кылып торучы урта хәллерәк кешене таптап та узарга мөмкиннәр. Ә теге бай бар дип тә белми. Файдасы да тими, әлбәттә. Әмма болар өметен өзми, бу юлы булмады инде, киләсендә берәр файда итәр дип уйлый.

Акыллы булу да фәкать акыллы булуны гына аңлата, кешегә башка сыйфатлар өстәми. Һәм барысыннан да бигрәк – бай булуны билгеләми. Россиядә бай булу өчен акыллы булу кирәкми. Шуңа күрә «акыллы булгач, нигә бай түгел» дигән сүз урысныкы да түгелдер, бу аңа чит илдән кергәндер дип уйларга кирәк. Акыл көчен бәяли һәм кадерли ала торган илдән.

Ә бүгенге Россиядә кешене бай дип әйтү кимсетү кебек яңгырый. Ул нибары бер генә ассоциация тудыра – карак, җинаятьче. Ну, йомшаграк әйтсәк, мошенник, жулик, спекулянт. Чөнки бүгенге миллиардерларның күпчелеге – нәрсәдер җитештереп, юкны бар итеп, дәүләткә һәм илгә файда китереп баеган шәхесләр түгел, ә СССРның байлыкларын урлап, талап, алдашып кулга төшергән паразит сыман нәрсәләр. Һәм мондый каракларга бернинди хөрмәт тә, ихтирам да була алмый.

Һәрхәлдә... Булмаска тиеш...

Ләкин...

Илдә мөлкәт культы хөкем сөрә... Кая карама – уңышлылыкны, хөр тормышта яшәү рәвешен данлаган спектакльләр... Байлык, муллык, җитеш тормыш алдында баш июләр... Миллионерлар рейтингы... (Белмим, кемгә, ни өчен кирәктер алар? Кемнәр комсызрак һәм намуссызрак икәнен билгеләү өчен түгелдер ич инде?) Кайсы илдә ял итүе, нинди машинада йөрүе, ничә сумлык күлмәкләр киюе белән мактанучы сәнгать әһелләре. Кабатлап әйтәм, сәнгать әһелләре! Туктаусыз рәвештә байлыкка мәдхия яудыручы телетапшырулар... байлар тормышын тасвирлаган санап бетергесез телесериаллар... Болар барысы да мөлкәт культы булдырырга, акча турында гына уйлый торган кешеләр тәрбияләргә хезмәт итә. Бигрәк тә гомумхәерчелек фонында.

Бүген халыкның күбесе кредит, квартплата һ.б. шундый бурычлар түләүдән ерак китми торган хезмәт хакына эшләп йөри. Һәм ничә сум зарплата алганын кычкырып әйтергә гарьләнә. Чөнки акча, мөлкәт культы белән сугарылган җәмгыятьтә аның хезмәт хакы бик кечкенә, ә үзе бик булдыксыз булып күренә. Шуңа күрә байлык культы хакимнәр өчен бик отышлы. Ул халыкны иң арзан хак түләп эшләтергә, энәсеннән җебенә кадәр таларга мөмкинлек бирә. Һәм беркем дә каршы килмәячәк, беркем канәгатьсезлек белдермәячәк. Чөнки мөлкәт культы идеаль халәт хасил иткән: халык үзенең хәерче булуыннан ояла, моны ныграк яшерергә, баерак булып күренергә тырыша. Бу исә аны тагы да ныграк бәйли, һәртөрле бурычларга, кредитларга керәп батарга мәҗбүр итә.

Менә бу мохиттә инде адәм баласы үзенең шәхес булуын онытып, үрдә искә алынган төркемнең дөньяга мещан күзләре белән карый торган сантыйрак төркемнең бер вәкиленә әйләнә. Бай кеше алдында өлтерәп тора ул. Һәм әлеге байлыкның ничек барлыкка килүенә битараф булып кала. Икенче төрле әйтсәк, байлыкка хәләл тиреңне һәм акыл көчеңне түгеп ирешү дә, җинаять аша, алдашып, урлашып яки үтереп хуҗа булу да – аның өчен барыбер. Иң мөһиме – соңгы нәтиҗә. Ә бу куркыныч. Чөнки бай булганың өчен нидер өмет итеп бүген синең тирәңдә бөтерелеп торган бәндә, өмете тәмам өзелгәч, мөлкәтеңне кулга төшерү нияте белән, иртәгә башыңа да җитәргә мөмкин... Хәтта эш ул дәрәҗәгә үк барып җитмәгән хәлдә дә әлеге төссез төркем вәкиле урлашу мөмкинлеген бернинчек тә кулдан ычкындырмаячак инде. Һәм ул аз гына матди өстенлек өчен теләсә кемне теләсә кемгә теләсә кайсы вакытта сатып җибәрәчәк.

Байлык культы хакимлек иткән җәмгыятьтә кеше үзен ярлы итеп тоя, аңа беркайчан да җитми... Байлык наркотик сыман бер нәрсәгә әверелә, аның дозасын арттыру таләп ителә башлый.

Шундый хәлләр. Чамасыз байлар яшәгән илдә дөньяга мещан күзләре белән карый торган сантыйрак бер төркем бар. Үз зурлыгы, үз авырлыгы, үз йөзе, үз кыйбласы булмаган төркем. Үз байлыгы булмаган төркем. Кайчагында мин шикләнеп куям, бүген гади халыкның барысы да шушы төркемгә керимме икән.

ҮЗЕМ КҮРДЕМ

Монда да чират ди

Берчакны эт эзләргә туры килде. Ана эт асрап, аны балалатып яткан кешене авыл җирендә очратмассың. Эзләнүләр авыл фермасыннан башланды дип тә әйтә алмыйм, чөнки аның таратылуына ун гына ел да түгел, күбрәктер. Киттек күрше авылга.

Тик андагы дуңгыз комплексында да һәм кечкенә генә фермаларында да этләр күренмәде. Дөресрәге, дуңгызлар янына тук йөзле көр каравылчы бөтенләй кертмәде. Ул тирәдә этләр булса, үзләре үк өреп каршыга йөгереп чыгарлар иде, дип, күрше районнан эзләргә булдык. Лаеште эт эзләү дә нәтиҗә бирмәде.

Юлыбыз Балык Бистәсенең Олы Елгасына таба борылды. Фермалары гөрләп эшләп ята. Атлар да күренә, сыерлары да һәм, ниһаять, этләре дә бар. Каршыга ук килеп чыктылар. Анда эшләүче бер абый гына, боларны алмагыз инде, фермадан алган эт бер дә җүнле-рәтле булмый бит, дип, безгә нигәдер каршы килде.

– Шәһәргә барыгыз, төзелештә кешеләргә бик ияләшкән чын сакчы этләр була, – ди.

Көчекләре дә бик кечкенә булганга, без моннан да этсез генә кайтып киттек. Авылда эт таба алмый йөр инде...

Шуннан соң бер-ике ай үтте. Эт мәсьәләсе онытылып торды. Бер матур көзге көндә Казанның Вознесение бистәсендәге тукталышта басып торганда зур гына бер өйнең капкасында «Этләр сатам» дигән игъланны күргәч, эт мәсьәләсе кабаттан яңарды. Кызык, менә бит ана эт тотып, аның балаларын сатып яшәүче кешеләр дә бар икән Казанда, дип тел шартлаттым. Эт проблемасы чишеләчәк болай булгач, дип сөенеп тә куйдым. Шунда бакчасына кул арбасы белән тирес чыгаручы хатынны автобус тәрәзәсеннән күреп алдым. Бераз баргач кына аның эт тиресе ташыганы башыма барып җитте. Бер сәгать үттеме-юкмы, теге хатынга шалтыратам. «Ярар проблема юк, нинди токым?» – ди бу. Ул бер-бер артлы тезеп киткән токым исемнәрен белсә дә шул өлкәдә махсус белеме булган кеше генә беләдер. Берсе дә безнеңчә түгел – әйтсәң, телең сынар. Кыскасы, югалып калдым.

– Бер дә аптырамагыз, аларның һәркайсына паспорт ясалган, барысы да тиешле медицина тикшерүе узган, шәҗәрәләре дә кулда, – дип тезеп салды этләр хуҗасы.

Авызым кибеп китте хәтта... Ничек инде шәҗәрә?

– Сезнең бер дә эт алганыгыз юкмы әллә? – дип сүзен дәвам итте телефонның теге ягындагы яңгыравык тавыш.

– Бар... Дөресрәге, сатып алганым юк, ә сез ничә сумга сатасыз?

Шәҗәрәләре дә булгач, бер 3-4 мең сорый инде хәзер дип көткән идем, җавап мине бөтенләй телсез калдырды.

– Иң очсыз дигән токым – 40 мең, ә яшенә карап – 60 меңнән 75 меңгә чаклы...

Мин исә, беркатлыланып: «Алучылар бармы соң?» – дип сорыйсы иттем.

– Бар, күп алалар, зур йортларны кемнәрдер сакларга тиеш бит. Чиратка алдан ук язылып куялар миңа, – дигән җавапны ишеткәч, тизрәк саубуллашу ягын карадым.

Җәмәгать, гафу итегез кәнишне! Сүз сыер, ат турында да бармый. Ә бәяләре... Кем уйлаган шундый хакка эт сатучылар һәм эт алучылар бардыр дип? Никадәр генә әйбәт булса да, эт эт бит инде ул.

Айсылу ИМАМИЕВА.

Үтеп барышлый

Равил САБЫР

Эт белсен...

Американнар белән урысларны чагыштырып сөйләгән иде берсендә телевизордан Михаил Задорнов.

– Менә, – ди сатирик язучы, – сез аларның фильмнарын искә төшерегез, бик зур куркыныч янаганда алар ни дип кычкыра? Дөрес! «Спасаем наши задницы!» – диләр. Ә без урыслар бу очракта нәрсә дип әйтәбез? «Спасаем наши души...» – дибез. Американ, әйтик, ишекне ачып бүлмәнең буш икәнен күрсә, нәрсә ди? «Nobody here». Ягъни бу бүлмәдә гәүдә юк. Алар өчен кеше – беренче чиратта body – гәүдә, арт сан. Ә без урыслар ни дибез буш бүлмәне күргәч? «Ни души...» Ягъни безнең өчен кешедә иң кадерле нәрсә ул аның арт саны түгел, ә җаны...

Задорнов телевизордан американнарны сүгүен дәвам итте, ә мин уйга калдым. Ишекне ачып бүлмәнең буш икәнен күрсә, татар нәрсә ди? «Эт тә юк монда!» – ди. Безнең өчен кеше эт булып чыгамыни?

Гомумән, татар кешесе нигәдер бу йорт хайванын бик өнәп бетерми. Телгә кергән әйтемнәрне генә алыйк. Әшәке, яман телле кешегә карата «эт авыз» диләр, кадерсез кеше турында икенче төрле «этка типсәң, аңа тия», дип әйтәләр, хуҗасызлык турында «эте дә баш, бете дә баш», саран кулына кергән малны «эт авызына кергән сөяк», бер күренеп, бер югалып торган кояш турында «эт кояшы», начарлык эшләү, аяк чалуны «этлек эшләү» диләр һ.б.

Ник алайдыр, югыйсә, эт кешенең иң якын дусты ич инде?! Йорт-хуҗалыкны чит-ятлардан саклый, аучыга кыргый җәнлекләрне аулап алырга булыша, хуҗасына бик тугрылыклы хайван. Тик шулай да татар этләрне яратмый нигәдер. 90нчы еллар уртасында безнең авылдагы бер абзый этенә Ельцин дигән кушамат биргән иде. Шулай итеп, ул үзенчә илбашына булган мөнәсәбәтен күрсәткәндер инде. Борис патшаның иң көчле чоры бу, «демократия чәчәк аткан» чак. Ишетүем-белүем буенча, аңа, ай-һай, ник алай иттең диюче булмаган. Киресенчә, бөтенесе моңа көлеп-шаярып кына карадылар.

Бүген берәрсе этенә хәзерге патша исемен кушса, ни булыр иде икән? Ә бәлки бардыр да андый мисаллар?..

Ә нәрсә? Идея бит бу! Әйтик, әгәр дә шул турыда пьеса язсаң? Алайса, сатира юк, сатира аз, диләр...

Исемен «president@» дип куярга булыр иде, хәзер андый исемнәр модада бугай. Эчтәлегенә килгәндә, әйтик, яшәп ята ди татар авылында бер ир. Исеме Гали булсын ди. Бик булдыксыз бер нәмәрсә ди бу, мәсәлән, кулыннан бер җүнле эш килми ди. Хатыны бертуктаусыз сүгә моны: «Эттән туган!» «Эт сырты!» «Эт дагалап йөрисең!» һ.б.

Көннәрдән бер көнне Гали эт баласы күтәреп кайта. Моның янына күршесе керә. Анысының исеме Вәли булсын ди. Гомер-гомергә үзара ярышып, бер-берсеннән көнләшеп яшәгәннәр ди бу икәү.

Вәли (керә-керешкә). Әллә эт баласы алдың?

Гали. Әйе, алып кайттым әле менә...

Вәли. Ни дип исем куштың соң?

Гали. Путин.

Вәли. Нәрсә-ә-ә?!!!

Гали. Ә ник шулкадәр исең китте?

Шунда Вәли күршесенә нинди «коточкыч хата» ясаганы турында аңлата башлый, ялгышын төзәтергә чакыра: «Төрмәгә ябып куялар син дуракны!» – ди. Галинең генә исе дә китми: «Андый заманнар узды инде хәзер, без ирекле илдә яшибез! Ул минем этем, ничек телим – шулай атыйм», – ди.

Вәли төкеренеп чыгып китә, бераздан Галине авыл советы рәисе чакырта. «Бармыйм, минем аңа йомышым юк, әйтер сүзе булса, үзе килсен!» – ди бу. Килә авыл советы рәисе, үгетләп карый Галине, тик тегесенең һаман үз кирәсе: «Мин этемә үзем теләгән кушаматны тактым – бетте китте! Имею право! Нигә аракыга аның исемен кушарга ярый, ә эткә ярамый?!»

Участковый килеп керә аннары, пистолетын Галинең борын төбендә уйнатып куркытып карый, барыбер бирешми теге «эт сырты». Участковый моны машинасына утыртып район прокурорына алып китә, тик икенче көнне Гали берни булмагандай кайтып төшә. Хәлләр белешергә дип кергән Вәлине күршесе эттән алып эткә салып сүгә-сүгә куып чыгара: «Йөрмә монда иснәнеп! Нишләп көчегемә башка исем кушыйм ди?! Бар бит инде аның кушаматы!» – ди.

Булдыра алмадылар болар дип, Вәли газетага хат язып җибәрә. Күп тә үтми, Казаннан журналист килеп төшә, Гали һәм аның гадәти булмаган кушаматлы эте турында мәкалә язып чыга. Шуннан соң авылга журналистлар көн дә килә башлый: башта бүтән газеталардан, аннары телевидениедән. Ахыр чиктә Галине федераль каналлардан күрсәтә башлыйлар, бик популяр кешегә әйләнә бу.

Телевизордан еш күренгәч, Гали сәясәтчеләр игътибарын да җәлеп итә үзенә. Моның янына төрледән-төрле партия вәкилләре килә башлый – коммунистлар, Жириновский «лачыннары», «эсерлар», «яшелләр», монархистлар, анархистлар һ.б. Һәрберсе үз фиркасенә чакыра, кемдер исемлектә – бишенче урынны, кемдер – өченчене, ә кайсыберләре төбәк исемлегендә хәтта беренче урынны да тәкъдим итә. Кыскасы, бик «олы», «хөрмәтле», «абруйлы» кешегә әйләнеп китә Гали, кисәк кенә. Күршесе Вәли биргән сәламнәрне алмый да башлый хәтта!

Вакыйгалар шулай көннән-көн куерып барганда, президент катнашында матбугат конференциясе уза. Анда хәзерге патшадан аның Галигә мөнәсәбәте, ә бигрәк тә этенә Путин дип кушамат бирүе турындагы фикерен сорыйлар.

«Как тут без татар? У нас без татар невозможно, – дип елмая Путин. – Особенно мне нравится их тонкий юмор. Может быть, вы не знаете, но я вам расскажу, что в этой деревне и в ее окрестностях всех собак зовут именами политических лидеров. Там и Наполеон есть, и Меркель, и Обама, и Клинтон, и Мамай, и Ширак – кого только там нет?! Ну, вот такая у них там традиция сложилась. Поэтому нет ничего удивительного в том, что появилась собака по кличке Путин. Кстати, я и сам собак очень люблю. У меня и лабрадор есть, и болгарская овчарка, и японская акита-ину».

Президентның шушы җавабыннан соң Галигә булган бөтен игътибар шундук эреп юкка чыга. Ул янәдән беркемгә дә кирәкмәгән, кулыннан бер эш тә килмәгән бер мәхлукка әверелә. Бары тик участковый гына бәладән баш-аяк дип, һаман бораулап йөри Галине: «Алыштыр этеңнең кушаматын бер-бер хәл килеп чыкканчы! Миңа түгел, үзеңә кыен ашарга туры килә бит!» – ди.

Берсендә шулай килеп чираттагы мәртәбә тәрбияви лекция укый башлагач, Гали ачу белән җавап бирә участковыйга:

– Ярар тынычлан инде! Синеңчә булыр, башка исем кушам!

– Ни дип кушасың, Гали?

– Ниту!

– Нәрсә ниту?

– Ниту дигән кушамат тагам этемә. Ниту була кушаматы, юк дигән сүз татарча, аңладыңмы?!

– Үгез булмагае чурт булсын, балаларга сөт булсын, – дип кулын селтәп китеп бара участковый.

Ә Гали буяу белән пумала ала да эт оясына зур хәрефләр белән «НИТУ» дип яза. Аннары бераз як-ягына карангалап торгач, хәйләкәр елмая да «П» хәрефен дә өстәп куя...

Йә, сезнеңчә ничек? Шундый пьеса язылса, берәр театр алыр иде микән аны спектакль итеп куярга? Режиссерлар ни дияр иде икән укып чыккач? Артистлар читкадан соң нинди фикерләр әйтер иде икән? Спектакль булып сәхнәгә менгән очракта тамашачылар ничек кабул итәр иде икән бу әсәрне? Ә тәнкыйтьчеләр, журналистлар? Эт белсен...

Хәер, минемчә, күбесе фикерләрен күңел төпкелләрендә генә калдырыр иде. Безнең милләт, урыс империясе басымы астында гасырлар буе изелеп яши-яши белгән-уйлаганнарының барысын да кычкырып әйтергә ашыкмаска, сабыр булырга өйрәнгән ул. Әйтик, менә шул ук: «Эт тә юк монда!» – дип әйтүгә кайтсак, әлбәттә инде, бу татар өчен кеше беренче чиратта эт булудан түгел бит. Һич юк! Татар кешесе ишекне ачкач, чынлыкта болай дип уйлый: «Кеше түгел, хәтта эт тә юк монда!» Ягъни җөмләнең беренче яртысы уйда гына кала, кычкырып әйтелми.

Башка халыкларда да шулай микән ул? Чагыштырып карасаң, кызык инде! Күптән түгел бер чит ил фильмы карап ятам. Героиня геройга әйтә: «Я верю в тебя, милый! Правда!» – ди. Татарчасы: «Мин ышанам сиңа, сөеклем! Чынлап!» Үлсә дә әйтми безнең татар мондый сүзләрне! Ул синең сөеклең булгач, син аңа ышангач, «чынлап» дип өстәргә ник кирәк инде? Башка вакытта син аңа уйнап кына ышанасыңмыни? Яки бөтенләй ышанмыйсыңмы? Әллә инде ул синең сөеклең түгелме? Ә нәрсә ди соң татар мондый очракларда? Бөтенләй берни дә әйтмәскә мөмкин, тик ул шундый мәгънәле итеп карап куяр, ул караштa барысы да язылган булыр...

Үз тәҗрибәмнән дә чыгып әйтәм моны. Ике-өч ел элек олы улым белән этләшеп алган идек бераз: ул үз киресен тукый, мин булдыра алганча аның ялгышканлыгын аңлатырга тырышам. Беркемнең дә бирешәсе килми, мин исә артык нык басым ясамаска тырышам, ә бәлки мин хаклы түгелдер? Ахыр чиктә бер фикергә килә алдык, мәсьәлә чишелде, үзара мөнәсәбәтләр җайга салынды. Күпмедер вакыт узгач, улым социаль челтәрләрнең берсендәге сәхифәсенә дөньякүләм билгеле футболчы Зинеддин Зиданның фотосын һәм ул кайчандыр әйткән сүзләрне урнаштырган: «Әтиемнең миңа беркайчан да: «Мин сине яратам», – дигәне булмады, тик аның эш-гамәлләреннән дөньяда иң яраткан кешесе мин икәнен гел белеп тордым».

Бу сүзләрне мин укыганны улым аңлагач, алар сәхифәдән юкка чыкты. Мин башта аның бу гамәлен аңламадым, соңрак кына төшендем: бу сүзләр бары тик бер кешегә генә адресланган булган бит. Менә шундый инде ул татар күңеле – эт ерып чыккысыз. Кайчак әйтелгән сүзгә караганда, әйтелмәгәнә мөһимрәк. Әйтмә дә инде, малай...

Әлмәт, 2017 ел, март

СӘЛАМӘТЛЕК

ИКЕНЧЕ ӘНИ

Россиянең иң яхшы балалар табибы – Татарстаннан

Мәскәүдә узган Россия педиатрлар съездында «2016 елның балалар табибәсе» дип 65 меңнән артык белгеч арасыннан Түбән Кама шәһәре балалар хастаханәсе перинаталь үзәгендә эшләүче Татарстанның атказанган табибы Гадилә Җиһангәрәеваны сайлап алдылар. Ул бу өлкәдә инде 54нче елын эшли. Ә Җиһангәрәевләр династиясенең медицина өлкәсендә гомуми эш тәҗрибәсе 100 елдан артып китә.

Эльвира МОЗАФФАР

– Мәскәүдә, Россия педиатрлар берләшмәсенең 90 еллыгы уңаеннан, «Педиатрия өлкәсендәге актуаль проблемалар» хакында сөйләшергә җыелган идек. Конференция кысаларында 100 процент тавыш җыеп, елның иң яхшы табибы итеп нәкъ менә мин сайландым. Бу үзем өчен дә көтелмәгән хәл булды. Баштарак шок хәлендә йөрдем. Германия, Австрия, Израиль кебек чит илләрдән, төрле төбәкләрдән килгән тәҗрибәле белгечләр алдында Татарстан табибының җиңүе зур горурлык, дәрәҗә дип саныйм. Димәк, хезмәтемне аңлыйлар, бәялиләр, 54 ел тик кенә тормаганмын, кемгәдер файда китергәнмен, – ди тыйнак Гадилә ханым.

ИҢ ЗУР БҮЛӘК – БАЛАЛАРНЫҢ ЕЛМАЮЫ

Аны еш кына «энциклопедия» белән чагыштыралар. Акыллы, тырыш, мәрхәмәтле, тәҗрибәле булганы өчен, ул коллегалары, шәһәр халкы арасында хөрмәт казанган. Ә балалар аны «Икенче әни» дип йөртә. Йөзеннән елмаю китмәгән ягымлы табибны һәр кечкенә пациент яратып каршылый. Россия күләмендә ел табибы исемен алуы җиңүләренең иң зурысы булса да, тәүгесе түгел. 2015 елда ул республика күләмендәге «Ак чәчәкләр» бәйгесендә «Ел табибы» номинациясендә беренчелекне алган иде. Хезмәтендәге уңышлары өчен бирелгән диплом, грамоталарының чуты юк. «Шулай да иң зур бүләк – савыккан балаларның, аларның әти-әниләренең елмаюлы карашларын күрү, эшенең нәтиҗәсеннән рәхәтлек алу», – ди Гадилә Зиннәтулла кызы.

Җиһангәрәевләр нәселендә медицина юлын сайлаган беренче кеше була Гадилә ханым. Хәер, кечкенә чагында ул укытучы йә артист булам дип хыяллана.

– Йолдызнамәдә, кучкарлардан яхшы укытучылар, артистлар йә табиблар чыга, диелгән. Кечкенә чакта укытучыбыз Анна Петровна булып уйнасам, концертлар килгән саен, сәхнәгә менеп җырлыйсым килеп кала иде. Югары классларда Түбән Тәкәнеш авылы мәктәбендә укыганда, медицина тикшерүе уздык. Ак халатлы, йөзеннән нур бөркелеп торган фәрештәдәй фельдшер Факиһә апаны күреп, медицина өлкәсенә кызыксыну уянды. Мәктәпне тәмамлауга, ике дә уйламый, дустым Надя белән Казан медицина университетына киттек. Химия укытучысына рәхмәт, ул фәнен яхшы аңлатты, имтихан вакытында да биремнәрне бер дәфтәр яздым. Укырга кердек, дип сөенеп кайттык. Әтинең шул чакта: «Алты ел – кеше гомере… Укытучы булсаң, утын бирерләр иде, ичмасам (ул чакта мөгаллимнәргә утын бирәләр иде)», – дигәне хәтердә. Ләкин медицина юлын сайлавыма бер дә үкенмим, бик күңелле укыдык, – дип, яшьлек елларын искә ала Гадилә ханым.

«ОПЕРАЦИЯ ВАКЫТЫНДА ШӘМ ТОТЫП ТОРДЫЛАР»

Җиһангәрәевләр гаиләсе Самара өлкәсендә яшәп ала. Анда Гадилә ханым Новокуйбышевск сырхауханәсендә эшли. Татарстанда яңа шәһәр – Түбән Кама төзелгәнне белеп, алар туган якларына кире кайтырга уйлый. Ул чакта бүгенге яшел, якты матур шәһәрнең эзе дә булмый әле. Төзелеш гөрли, соры йортлар, будкалар, асфальт салынмаган юллар, бар җирдә пычрак. Хастаханә дә юк. Авыруларны беркатлы баракта кабул итәргә туры килә. Балалар, төрле авырулы олылар, акыл ягыннан зәгыйфьләр дә бер бинада дәвалана.

– Беренче мәлдә Новокуйбышевскстагы коллективымны бик сагындым. Ул чакта кызым Гүзәлгә биш ай гына, декрет еллары юк, баламны тирбәтә-тирбәтә, пациентларны кабул иткән чаклар да булды. Педиатр булсам да, төрле авыруларны кабул итәргә туры килде, – ди Гадилә ханым.

Бер вакыйга бүген дә исеннән чыкмый аның. Авыр хәлдә бер хатын-кызны китерәләр. Авыруның йөрәк тибеше акрынайган, эче нык авырта. Шунда ук аңа операция ясарга керешәләр. Педиатр булуына карамастан, Гадилә ханымга да булышырга туры килә. «Ул чакта дөрес эшләргә тырышуым, кулымдагы киеренкелекне бүген дә сизәм кебек», – ди табиб, чөнки операция барышында кинәт ут сүнә. Барлык шәфкать туташларына, санитаркаларга шәмнәр кабызып, катлаулы шартларда эшләргә туры килә. Шөкер, операция уңышлы төгәлләнә. Бу хатын бүген дә исән-сау. Ул еллар Гадилә ханымга зур тәҗрибә мәктәбе була.

Кызганыч, бүген яшьләр арасында шәһәр хастаханәсенә кайтучылар сирәк, дип борчыла табиб. Белгечләрне чакырып, Ижау, Уфага мөрәҗәгать итәргә дә туры килә икән. Балалар табибы булу җиңелләрдән түгел шул. Гадилә ханым фикеренчә, бу һөнәрдә беренче чиратта сабыр, түзем булу сорала. Күпмедер дәрәҗәдә психолог булу да кирәк.

– Педиатр балалар белән генә түгел, аларның әти-әниләре, әби-бабайлары белән дә эшли. Хәзер күпләргә интернет тәэсир итә. Төрле форумнардан дәвалану турында укыйлар да табибның үзен өйрәтергә керешәләр. Һәр баланың организмы үзенчәлекле ләбаса. Интернеттагы мәгълүматка гына таянырга ярамый. Барысын да бәйнә-бәйнә аңлатырга туры килә. Балалар төрле – күкрәк сабыйлары, балалар бакчасына, мәктәпкә йөри торганнары, үсмерлек чорына җиткәннәре бар. Һәрберсе белән уртак тел табарга кирәк. Эшеңне яратып башкаруыңны балалар да сизә, – ди Гадилә ханым.

БАЛАЛАРГА НАЗ ҖИТМИ

– Бүген балаларда нинди авырулар күбрәк очрый?

– Ашказаны белән бәйле авырулар бик күп. Балалар дөрес тукланмый: фасфуд, майонез кебек зыянлы ризыкларны күп ашый. Бу исә организмга тәэсир итми калмый. Шулай ук мәктәптәге киеренкелек, буш вакытның аз калуы, яшьтәшләре арасындагы конфликтлар да эзсез узмый. Үсмерләр арасында тәмәке тартучылар шактый. Тагын бер популярлашкан авыру – аллергия. Бу экология, эчә торган суның сыйфаты белән дә бәйле. Балаларның нерв системасында тайпылышлар ачыклану очраклары да ешайды. Монысын гаиләдәге мохит белән дә бәйләргә була. Күп ата-аналарның балаларга игътибары җитми, вакытлары юк. Бала стресс кичерә. Бу, үз чиратында, нерв системасын какшата. Нәкъ менә стресс вакытында нәселдән күчәргә мөмкин булган авырулар барлыкка килү куркынычы арта.

– Баланың иммунитетын ничек ныгытырга?

– Әгәр дә бала елына алты тапкырдан да күбрәк чирли икән, ул еш авырый торганнар исемлегенә керә. Бу очракта иммунологка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Гадәттә, яңа туган сабыйларның иммунитетлары формалашмаган була. Ике-дүрт яшьтә балалар бакчасына йөргәндә еш авырыйлар. Кешеләрнең дөньясы үзгәргән шикелле, микроблар да төрләнә. 14-17 яшьтә дә иммунитет көчсезләнә. Яшьләр компьютерда, телефонда еш утыра, аз хәрәкәтләнә. Көне буе утырып торганда, бер җир дә эшләми: үт куыгы да, ашказаны да… Ничек кенә булмасын, бала еш авырганда белгечләргә күренеп, дөрес дәвалану, организмны ныгыту чараларын сорарга кирәк.

Гадилә Җиһангәрәеваның ике кызы да әнисенең юлын дәвам итә. Гүзәле – Түбән Кама балалар хастаханәсе перинаталь үзәгендә баш табиб урынбасары. Гөлназы – медицина фәннәре кандидаты, «АК Барс- Мед» иминиятләштерү компаниясендә медицина ярдәме сыйфатын контрольдә тоту идарәсе башлыгы. Җиһангәрәевләр гаиләсенең медицина өлкәсендә гомуми эш стажы – 105 ел.

Гадилә апа буш вакытларында мәдәни чараларга йөри. Рудольф Нуриев исемендәге Халыкара фестивальне калдырмый, Татар дәүләт опера һәм балет академия театрындагы премьераларны да карап бара. Үзе дә моңлы итеп җырлый. Сүз уңаеннан, Түбән Камада узган шәһәр бәйгесендә «Иң матур язучы табиб» дип танылган. «Аның язуы кайбер рус теле укытучыларыныкыннан да тигезрәк, пөхтәрәк, аңлаешлырак», – ди коллегалары.

ГАДИЛӘ ҖИҺАНГӘРӘЕВАДАН БАЛАНЫҢ ИММУНИТЕТЫН НЫГЫТУ ӨЧЕН КИҢӘШЛӘР

- саф һавада күбрәк булырга;
- дөрес тукланырга;
- әти-әниләргә балага карата назын, игътибарын кызганмаска, мәхәббәтен ешрак белдереп торырга;
- бала еш авырганда табиб белән киңәшләшеп, иммунитетны ныгыта торган махсус препаратлар, витаминнар бирү кирәк. Шулай ук үләннәр ярдәмендә сәламәтлекне ныгыту да файдалы. Әйтик, кура җиләге яфрагы иммунитетны ныгыта.

27 МАРТ– ДҮШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Җырлыйк әле!» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Фурцева. Легенда о Екатерине» . Телесериал (16+)
10:00 «Иkенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Разведчицы». Телесериал (16+)
13:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
14:00 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Кучтәнәч» (0+)
15:15 «Без тарихта эзлебез» (6+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:05 «Кафе «Парадиз». Телесериал (12+)
17:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
17:40 «Татарстан без коррупции» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Кучтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Митей Бурмистровым» (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Әдәби хәзинә» (12+)
08:30 «Яшьсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:05 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Татарлар» (12+)
11:30 «Бeлем дөньясы» (6+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Без тарихта эзлебез» (0+)
14:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Кучтәнәч» (0+)
15:30 «Тамчы-шоу» (0+)
16:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Халкым минем» (12+)
19:40 «Родная земля» (12+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Кучтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.40 «Парламентские вести»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Мата Хари». (16+)
23.30 «Вечерний Ургант». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
13.00 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия-10». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Две жизни». (12+)

28 МАРТ– СИШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Музыкаль каймак» (12+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Фурцева. Легенда о Екатерине» . Телесериал (16+)
10:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Родная земля» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Разведчицы». Телесериал (16+)
13:00 «Путь» (12+)
13:15 «Рыцари вечности» (12+)
13:30 Документальный фильм (12+)
14:15 «Дорога без опасности» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Кучтәнәч» (0+)
15:15 «Әдәби хәзинә» (12+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:05 «Кафе «Парадиз». Телесериал (12+)
17:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
18:45 Хоккей. Кубок Гагарина. «Ак Барс» – «Металлург».Трансляция из Казани (12+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Азатом Кадыровым» (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Без тарихта эзлебез» (0+)
08:30 «Яшьсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:20 «Җырлыйк әле!» (6+)
11:10 «Татарлар» (12+)
11:30 «Халкым минем» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Әдәби хәзинә» (12+)
14:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Кучтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Башваткыч» (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Кучтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:45 ТВ фондыннан. Г.Ибраhимов. «Яшьташлар». Телефильм. Икенче серия (12+)
23:35 «Яшьсен театр!» (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Радовые России»
9.25 «Дороже богатства»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
19.00 Футбол. Сборная России - сборная Бельгии. Товарищеский матч. Открытие стадиона «Фишт». Прямой эфир.
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Мата Хари». (16+)
23.30 «Вечерний Ургант». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
13.00 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия-10». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Две жизни». (12+)
21.55 Т/с «Две жизни». (12+)

29 МАРТ– ЧӘРШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Таяну ноктасы» (16+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Дорога в пустоту» . Телесериал (16+)
10:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Ватандашлар». Телефильм (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Ветреная женщина». Телесериал (16+)
13:00 «Каравай» (0+)
13:30 Документальные фильмы (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Кучтәнәч» (0+)
15:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:05 «Кафе «Парадиз». Телесериал (12+)
17:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
17:30 «Трибуна «Нового Века» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Кучтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Әдәби хәзинә» (12+)
08:30 «Яшьсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:20 «Башваткыч» (6+)
11:10 «Татарлар» (12+)
11:30 «Родная земля» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Без тарихта эзлебез» (0+)
14:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Кучтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Таяну ноктасы» (16+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Кучтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Инквизитор». (16+)
23.30 «Вечерний Ургант». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
13.00 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия-11». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Две жизни». (12+)

30 МАРТ– ПӘНҖЕШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Башваткыч» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Дорога в пустоту» . Телесериал (16+)
10:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Белем дөньясы» (6+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 « Ветреная женщина». Телесериал (16+)
13:00 «Каравай» (0+)
13:30 Документальный фильм (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Кучтәнәч» (0+)
15:15 «Әдәби хәзинә» (12+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:05 «Кафе «Парадиз». Телесериал (12+)
17:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
18:45 Хоккей. Кубок Гагарина. «Ак Барс» - «Металлург». Трансляция из Казани (12+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Без тарихта эзлебез» (0+)
08:30 «Яшьсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:15 «Таяну ноктасы» (16+)
11:10 «Татарлар» (12+)
11:30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Әдәби хәзинә» (12+)
14:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Кучтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Көн сәгате» (12+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Кучтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.40 «Вести-Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
9.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Инквизитор». (16+)
23.30 «Вечерний Ургант». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
13.00 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия-11». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Две жизни». (12+)

31 МАРТ– ҖОМГА

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Халкым минем...» (12+)
05:25 «Насыйхәт» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник » (12+)
09:00 «Дорога в пустоту» . Телесериал (16+)
10:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Насыйхәт» (6+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Ветреная женщина ». Телесериал (16+)
13:00 «Башваткыч» (6+)
14:00 «Актуальный ислам» (6+)
14:15 «Профсоюз – союз сильных» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Кучтәнәч» (0+)
15:15 «Тамчы-шоу» (0+)
15:40 Мультфильмы (0+)
15:55 «Зебра» (0+)
16:05 «Кафе «Парадиз». Телесериал (12+)
17:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
18:00 «Туган җир» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Белем дөньясы» (6+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Кучтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Насыйхәт» (6+)
08:30 «Яшьсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Музыкаль каймак» (12+)
10:00 «Караоке татарча» (0+)
10:15 «Көн сәгате» (12+)
11:10 «Татарлар» (12+)
11:30 «Кичке аш» (6+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Насыйхәт» (6+)
14:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Кучтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Йолдызлар да төшеләр җирга...». Татарстанның халык артисты Хәмдүнә Тимергалиеваның иҗат кичәсе (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Кучтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Иҗат»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20 «Вести Приволжского федерального округа»
20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 Жди меня.
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.45 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым. (16+)
19.50 «Поле чудес». (16+)
21.00 Время.
21.30 «Голос.Дети». Новый сезон.

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
13.00 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия-11». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 «Петросян-шоу». (16+)

1 АПРЕЛЬ– ШИМБӘ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Концерт (6+)
07:00 «Сиңа Миннән Сәлам» (6+)
09:30 «Автомобиль» (12+)
10:00 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Халкым минем...» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Каравай» (0+)
12:30 «Видеоспорт» (12+)
13:00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
13:30 «Созвездие – Йолдызлык-2017» (0+)
14:30 «Миңа да – 30! Данир Сабиров». Җырлы-биюле юмористик тамаша (12+)
17:30 «Татарлар» (12+)
18:00 Волейбол. Женщины. Кубок ЕКВ. «Динамо-Казань» – «Галатасарай»(Стамбул). Трансляция из Казани (6+)
19:30 Новости в субботу (12+)
20:00 «Адымнар» (12+)
20:30 «Җырлыйк әле!» (6+)
21:30 Новости в субботу (12+)
22:00 «Красавица из трущоб». Художественный фильм (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Яшьлек дәрте яши йөрәгемдә!». Татарстанның халык артисты Хәмдүнә Тимергалиеваның иҗат кичәсе (6+)
07:00 «Сиңа Миннән Сәлам» (6+)
09:30 «Шаян хәлләр» (16+)
10:00 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Башваткыч» (6+)
11:50 «Җырлыйк әле!» (6+)
12:40 Г.Камал. «Банкрот». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле (12+)
14:30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
15:00 «Сиңа Миннән Сәлам» (6+)
17:30 «Насыйхәт» (6+)
18:00 «Таяну ноктасы» (16+)
18:55 «Кичке аш» (6+)
19:20 «Башваткыч» (6+)
20:10 «Җырлыйк әле!» (6+)
21:00 «Адымнар» (12+)
21:30 «Ачы корты». «Мунча ташы» эстрада театры спектакле (16+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
8.00, 11.20 «Вести – Татарстан»
8.20 «Доброе утро, Татарстан!»

ПЕРВЫЙ
06.00 Новости.
06.10 Х/ф «Семь невест ефрейтора Збруева». (12+)
08.00 Играй, гармонь любимая!
08.45 М/с «Смешарики. Новые приключения».
09.00 Умницы и умники. (12+)
09.45 Слово пастыря.
10.00 Новости с субтитрами.
10.15 Д/ф Премьера. «Мата Хари. Шпионка, которую предали». (12+)
11.20 Премьера. «Вокруг смеха».
12.00 Новости с субтитрами.
12.20 Премьера. «Вокруг смеха».
14.20 Х/ф «Солдат Иван Бровкин».
16.10 «Голос. Дети».
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.15 «Кто хочет стать миллионером?» с Дмитрием Дибровым.
19.10 «Минута славы». Новый сезон.
21.00 Время.
21.20 «Сегодня вечером» с Андреем Малаховым. (16+)

РОССИЯ 1
05.15 Т/с «Чокнутая». (12+)
07.10 «Живые истории».
08.00 Вести. Местное время.
08.20 Россия. Местное время. (12+)
09.20 Сто к одному.
10.10 «Пятеро на одного».
11.00 Вести.
11.20 Вести. Местное время.
11.40 Аншлаг и Компания. (16+)
14.00 Вести.
14.20 Х/ф «Операция «Ы» и другие приключения Шурика».
16.20 «Золото нации».
18.00 Субботний вечер.
20.00 Вести в субботу.
21.00 Х/ф «Второе дыхание». (12+)

2 АПРЕЛЬ– ЯКШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Концерт (6+)
08:00 «Адымнар» (12+)
08:30 Мультфильмы (0+)
09:00 «ДК» (12+)
09:15 Документальный фильм (12+)
09:45 «Тамчы-шоу» (0+)
10:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
10:45 «Музыкаль каймак» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Яшьлегем хисларе». Венера Ганиева концерты (0+)
12:30 «Каравай» (0+)
13:00 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
13:30 «Адымнар» (12+)
14:00 «Созвездие – Йолдызлык-2017» (0+)
15:00 «Көн сәгате» (12+)
16:00 «Җырлыйк әле!» (6+)
17:00 «Видеоспорт» (12+)
17:30 «Әдәби хәзинә» (12+)
18:00 «Башваткыч» (6+)
19:00 Телефильм (12+)
19:30 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
20:30 «Болгар радиосы» концерты (6+)
21:30 «Кичке аш» (6+)
22:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Ватандашлар» (6+)
06:30 «Сөю кабатланмый». Нәфкать Нигъмәтуллин концерты (12+)
09:25 «Яшьләр тукталышы» (12+)
09:55 «Тамчы-шоу» (0+)
10:20 «Поем и учим татарский язык» (0+)
10:30 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
11:00 «Белем дөньясы» (6+)
11:30 «Халкым минем» (12+)
12:00 «Ах, бу гомерләр». Зөһрә Сәхәбиева җырлый (6+)
12:30 «Татарлар» (12+)
13:00 «Насыйхәт» (6+)
13:30 «Әйда, халыкка хезмәтка». Телефильм (6+)
13:50 «Житте шундый вакытларым». Зөһрә Шарифуллинаның юбилей концерты (6+)
16:30 «Музыкаль каймак» (12+)
17:20 «Әдәби хәзинә» (6+)
17:50 «Без тарихта эзлебез» (0+)
18:20 «Болгар радиосы» концерты (6+)
19:10 «Көн сәгате» (12+)
20:05 «Миңа да 30!». Данир Сабиров (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
10.20 «Вести – Татарстан. События недели»

ПЕРВЫЙ
06.00 Новости.
06.10 Х/ф «Иваново детство».
08.05 М/с «Смешарики. Пин-код».
08.25 «Часовой». (12+)
08.55 «Здоровье». (16+)
10.00 Новости с субтитрами.
10.15 «Непутевые заметки» с Дмитрием Крыловым. (12+)
10.35 «Пока все дома».
11.25 Фазенда.
12.00 Новости с субтитрами.
12.20 Премьера. «ТилиТелеТесто» с Ларисой Гузеевой.
13.55 Д/ф «Теория заговора». (16+)
15.00 Д/с «Романовы». (12+)
17.10 Концерт к Дню войск национальной гвардии РФ.
19.25 Премьера. «Лучше всех!»
21.00 Воскресное «Время».
22.30 «Что? Где? Когда?»

РОССИЯ 1
05.05 Т/с «Чокнутая». (12+)
07.00 Мульт-утро.
07.30 «Сам себе режиссёр».
08.20 «Смехопанорама» Евгения Петросяна.
08.50 Утренняя почта.
09.30 Сто к одному.
10.20 Местное время. Вести-Москва. Неделя в городе.
11.00 Вести.
11.20 Х/ф «Операция «Ы» и другие приключения Шурика».
13.10 «Семейный альбом». (12+)
14.00 Вести.
14.20 Х/ф «Ищу мужчину». (12+)
18.00 «Танцуют все!»
20.00 Вести недели.
22.00 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)

Первый, Россия1 каналларының программасы «Сервис-ТВ» АҖдан алынды

ФГБОУ ВО «КАЗАНСКИЙ ГОСУДАРСТВЕННЫЙ АГРАРНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ» ОБЪЯВЛЯЕТ КОНКУРС НА ЗАМЕЩЕНИЕ ВАКАНТНЫХ ДОЛЖНОСТЕЙ ПРОФЕССОРСКО-ПРЕПОДАВАТЕЛЬСКОГО СОСТАВА

1. Доцентов кафедр:

– физика и математика – 1

Ученый совет Института Механизации и Технического сервиса состоится 11 мая 2017 года.

Срок подачи заявлений – один месяц со дня опубликования в газете.

АДРЕС: 420015, г. Казань, ул. К. Маркса, 65.

«ТАТАРСТАН» радиосы

27 МАРТ – ДҮШӘМБЕ

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы
6.04 «Нефть чыккан якларда»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35, 10.00, 18.10 Яңалыклар. Новости
6.45 «Юллар чатында»
6.50,7.50,10,55,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.20 «Күңел кузгалган мәлләрдә»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.10 Кыска хикәяләр. Айдар Хәлим әсәрләре
18.25 «Сердәшханә»
18.40 «Жыр – минем гомерлек юлдашым».

28 МАРТ – СИШӘМБЕ

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий
6.04 «Актуальное интервью»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50, 7.50, 10.50, 13.55, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Диалог в прямом эфире
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Депутатский канал»
12.10 «Татарстан дулкынында»
13.20 Концерт
18.25 Ренат Харис шигырьләренә җырлар, романслар

29 МАРТ – ЧӘРШӘМБЕ

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы
6.04 «Нефть чыккан якларда»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,10.10,10.50,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.20 «Актуальное интервью»
10.35 «Старт»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Эстрада ритмнары

30 МАРТ – ПӘНҖЕШӘМБЕ

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий
6.04 «Перекресток»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Диалог в прямом эфире
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Доброе братство лучше богатства» (на мордовском языке)
10.35 «Время молодых»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 «Офыклар»
18.25 Рәдиф Гаташ шигырьләре буенча радиокомпозиция

31 МАРТ – ҖОМГА

6.00-8.00 «Иртәнге нур»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Вдохновенья миг»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 Концерт
18.25 Башкортстан артистлары концерты

1 АПРЕЛЬ – ШИМБӘ

10.10 «Табигать дуслары»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55,13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-15.10,16.00 Трансляция радио России
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында».
13.10 Татар халык көйләре
15.10 А.Островский. «Агай – эне ак мыек». Г.Камал ис.ТДАТ спектакле. 1нче өлеш

2 АПРЕЛЬ – ЯКШӘМБЕ

8.00-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10,11.00-12.10, 13.00-13.10, 14.00-15.10,16.00-16.10,17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий
10.55,13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.10 Ял концерты
15.10 «Тел күрке – сүз»

БУ – КЫЗЫК!

Тормышның төбеннән күтәрелү

✔ Чарли Чаплин тегүче һәм сәрхуш гаиләсендә туган. Ире әчеп үлгәннән соң, Чарлиның әнисе акылдан яза. Ике бала ятим кала. Биш яшендә Чарли, чарасызлыктан, эшләргә мәҗбүр була: газеталар тарата, типографиядә булыша, сәхнәләрдә чыгыш ясый. Мәктәптә укымаганлыктан, укый, яза да белми. 14 яшендә аңа кинога төшү өчен роль бирәләр, әмма ул сценарийны укый алмый. Тора-бара, тырышлыгы нәтиҗәсендә, ул үзенә юл яра...

✔ Apple компаниясенә нигез салучы Стивен Джобс дуслары янында тулай торак идәнендә йоклаган, ә иртән буш шешәләр тапшырып җыйган акчасына ашарга сатып ала торган булган...

✔ Байлыгы 3 миллиард доллар булган, шоу-бизнеста эшләүче хатын-кыз Опра Уинфриның бала чагында кияргә киеме дә булмаган. Әтисе – шахтер, ә әнисе асрау булган. Гаилә ярлылыкны бик авыр кичергән, шуңа күрә Опраны әбисе тәрбиягә алган. Үзенең ихтыяр көченә, булдыра алачагына, тормышын уңай якка үзгәртәчәгенә нык ышанган Опра, дөрестән дә, зур уңышларга ирешкән, байлык туплаган. Аны ярлылык баткаклыгыннан чыгып, үз-үзенә юл ярган бөек кешеләр исемлегенә кертергә мөмкин.

✔ Елына 30 миллион доллар акча эшләүче комик актер Джим Керри, бала чагында ачтан үлмәс өчен, бәдрәфләр һәм идәннәр юган. Еш кына чатырда куна торган булган. Үзенең ярлы бала чагын һәрчак шаяртып искә алган: «Мине ачлык чыныктырды», – дигән...

✔ Джордж Сорос урта хәлле гаиләдә туган. Ул кечкенә чакта, алар гаиләсен фашистлар эзәрлекли башлагач, чит илгә күчеп китәргә мәҗбүр булганнар. Сорос, бик яшь булуга карамастан, сатучы хезмәтеннән башкарган. Бай һәм атаклы кеше булу хыялы аны Лондонда икътисад (экономика) мәктәбен тәмамлауга этәргән. Хәзерге вакытта Джордж Сорос хәйрия эшчәнлеге белән үзен бөтен дөньяга танытты.

Нияз БИШБАЛТА
туплаасыннан,
Казан.

СКАНВОРД

Жырчы Эльвира
Крейсер
Кайбер Европа илләре акчасы
Ганди
«...-Дамм де Пари» мюзиклы
Мәркәзе – Багдад шәһәре
Аргамак
Жырчы ... Ильегет

Жайлы
Көлкеле
Мисыр җырчысы ... Диаб
Мәңге яшел ылыслы агач
Азиядә кеше ташучы
Бию-дәге ритмик хәрәкәт
Статуя
Крокет
Саф төс
Электр тогы көчен үлчәү берәмлеге
Бейсбол-да бер очко
Жәрәхәт
Газап
Аллегрова яки Салтыкова
Кояштан төшүче яктылык
Елан төре
Үлеп баручы дингез
Филип-пиндагы вулкан
Аны борын сизә
Кысынкы булмаган
Австралия-дә яшәүче сумкалы аю
Джеймс Кэмерон фильмы
Хәрәкәт итү әгъзасы
Атлантик
Очкыч
Элеп кую
Польша мәркәзе
Зәһәр ачы төтен
Күтәрү өчен спорт җиһазы
Милявская
Канар
Су буенда үсүче агач
Төн кошы
Күрешү
Болытсыз
Актриса ... Йовович
Тук түгел
Электр корылмалы атомнар төркеме
Сунар
Торак пункт
Япония шәһәре
100 м²
Товарның чиста авырлыгы
Татар ир-атлары исеме
Джерри-ның «дусты»
Балалар язучысы Абдулла

Юморис-тик ки-ножурнал
Пермь футбол клубы
Ак һәм кара төсләрдән торган
Ленар Сәйфиев җыры
Шприц
Житез
«... Роше»
Шрифт
Ризык

Фаил Гаязов төзеде

Горизонталь буенча: Титова, Индира, «Аврора», нарат, сын, рикша, ран, ампер, Ирина, Арал, яра, иркен, океан, ис, утрау, аяз, ач, аяк, ау, авыл, Лилияр, ион, Том, Асаев, «Амкар», «Ералаш», «Еракта», ала, тиз, «Ив», антиква, укол, ашамлык.

Вертикаль буенча: «Титаник», Лолита, тал, нур, Венера, ябалак, буар, крона, Икеда, рокки, ар, «Нотр», ак, очрашу, ипле, Ан, Ирак, асу, нетто, шаян, Раил, ат, Амр, Апо, па, Мила, иза, Алиш, Винарис, Варшава, ыс, коала, Альбина, авырлык.

Уртак хисләр

Башлык бүлмәсенә үгез муенлы, кыска кәкре аяклы, күлмәк якалары ат камыты шикелле ике якка ачылып китмәсен өчен аллы-гөлле чуар галстук бугап бер адәм килеп керде. Ул «Якты төн» күмәк хуҗалыгы персиятеле Моталлап иде. Йөзеннән гөрләвек булып тир ага, ә аркасыннан агып төшкән тир трусигына кадәр юешләткән.

– Калхуз бетте, Хан Солтанович, – диде персидәтел, мыш-мыш сулап. – Төнлә сыерларны алып чыгып бетергәннәр. Соңгы «Т-40» та күренми. Печән белән салам да юкка чыккан.

– Милициягә әйттеңме соң, пынимаешь? – диде башлык, һәрвакыттагыча бер җөмләсен вәкарь белән генә ике мәртәбә кабатлап.

– Әйттек-әйттек. Башта былтыр югалган сарыкларыгызны, дуңгызларыгызны табыйк әле, – диделәр. – Атлар, чәчкечләр, ургычлар да табылмаган. Шуларның очына чыксак, бәлки эзли башларбыз, – диделәр.

– Алайса, ник мине борчып йөрисең?

– Инде яши башлыйбыз дип кенә торганда бит, Солтаныч. Еллык хезмәт хакын бирәбез дип торганда...

Бу сүзләр башлыкның ачуын кабартты:

– Син нәрсә монда... нәрсә сырлап утырасың, тавык мие эчкән нәрсә! Син Бохар ишәгенә кем ышансын, анаңны сатыйм! Көпә-көндез шуның кадәр әйбер юкка чыга димени?

Кибән кебек кабарып утырган персидәтел, тылсымлы таяк белән суккан кебек урындыгына сеңеп, кечерәеп калды.

– Ур-ур-лау-у-у-ла-арын ни... ни... чек рас-с-с-ларга соң, Хан С-с...олтаныч?..

– Амбар кенәгәләрегез бардыр бит?

– Юк шул, кичә контурыбыз янды бит, Солтаныч.

Башлыкның борын тишекләре персидәтел сыярлык булып киерелде:

– Җыелыш җыеп, бераер нәрсә әмәлләп карагыз. Урладылар, янды дигәнгә ышаныргыз заманмы? Кәгазь кирәк, пынимаешь. Кыштырдаган кәгазь кирәк.

– Акчасы исән-сау ла аның анысы, – диде Моталлап. – Акча минем машинада иде.

– Аңлатыбрак сөйлә, – диде башлык.

– Сыерлары да күрше калхузда. Сарыклары да. Сыер да, сарык та булмагач, печән белән саламны, череп әрәм булмасын дип, үзем озаттым. «Т-40»ны гына аңлап бетермим. Каравылчы карт та белми...

– Әчәме?

– Кем?

– Каравылчы әчәме дим, дуңгыз?!

– Салгалый.

– Акчаны син бирәсеңме?

– Һы-ыһ!.. – адәм аңламаслык аваз чыгарып, персидәтел торып ук басты һәм таеп егыла язды, чөнки урындыгы астына әллә ботинка кары эреп, әллә башка җирдән агып, хәйран гына су җыелган иде.

– Син дә бирмәгәч, пынимаешь, мин дә бирмәгәч, каян табып эчә? Урлый, ызначит.

Шундый катлаулы мәсьәләнең җайлы гына чишелүенә килеп җиткән калхуз персие май кояшы кебек яктырып китте.

– Шул эчү аркасында инде, Солтаныч, эчү аркасында. Яши генә башлыйбыз дип торганда. Шул картка ышанып харап булдым. Кайту белән, каравылдан алып ыргытам мин ул карт тәрене. Аксак крич! Бөтен калхуз малын ничек эчеп бетермәк кирәк! Ни... Акчаны бары бер бирәбез, Солтаныч, быел булмаса, киләсе елга бирәбез.

Башлык шаркылдап көлеп җибәрде.

– Андый бәхет сиңа эләкмәс, – диде ул. – Бүгеннән синең хуҗалыкның исемен алыштырып, «Якты төн»нән «Караңгы көн»гә күчерәбез. Син әле яшь, энергияле белгеч. Әйдә, күрсәт үзеңне яңа хуҗалыкта.

Икесе дә торып бастылар. «Яшибез, яшибез!» – дип типте йөрәкләр. Аларның икесенең дә уйлары бер, хисләре уртак иде.

Фәрит ВАФИН.

Мин тал песие таптым, өемә алып кайттым.
Яныннан кат-кат үтәм – мияулаганын көтәм...

ЙОЛДЫЗ.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

ТАШКА БАСКАН

✓ Ирсез хатын – ауга чыккан арыслан, ирле хатын – каравылдагы эт.

* * *

✓ Хатын-кызлар җаваплылык кебек: алу – җиңел, качу – читен.

* * *

✓ Карсылулар салкын, тик тиз эри.

* * *

✓ «Кара көн»гә шундый нык әзерләнде һәм... аны түземсезлек белән көтә башлады... һәм көтеп ала алмады.

* * *

✓ Лекциядә йокласаң, армиядә уятырлар.

* * *

✓ Сөйгәнемнең «кияр нәрсә юк»ларын куяр нәрсә юк.

* * *

✓ Җаным, мин декабристка кебек, синең арттан теләсә кая барырга әзермен: хет Швейцариягә, хет Таиландка...

* * *

✓ Барысы да гырлаган гаиләдә йокы ярышы уза.

* * *

✓ Тотылмаган балык тиз үсә.

* * *

✓ Сөйгәнеңне «кайнатма», «парга әйләнергә» мөмкин.

* * *

✓ Кеше гомеренең 30 проценты йоклап, 70 проценты йокы туйдыру турында хыялланып уза.

* * *

✓ Даһилар – үлемсез, ахмаклар – мәңгелек.

* * *

✓ Кояш калка. Ләкин... Калыккан һәр нәрсә кояш түгел.

5 мәзәк

Ике әби поездда бер вагонда баралар икән. Беренче әби икенчесенә:

– Ахирәт, син кая барасың?

– Уфага, ә син кая барасың?

– Мин Уфадан кайтам!

* * *

Егет белән кыз талаша. Кыз, бик усал кыяфәт белән:

– Мин синең хатының түгел!..

Егет:

– Ә буласыңмы соң?

Кыз (шундый ук усаллык белән):

– Булам!

* * *

Урамда яшь ир янына матур гына бер хатын килә.

– Гафу итегез, сез минем бер баланың әтисе бугай?

Куркуга төшкән ир кеше:

– Минме?

– Тынычланыгыз, мин – укытучы.

* * *

– Карале, синең нибары өч сыерың бар, ә үзең көн саен иртән өчәр центнер сөт тапшырасың.

– Моның сере бик гади.

– Ягъни?

– Мин иртә белән сыерлар янына кергәч, бер генә җөмлә әйтәм: «Нишлибез: сөт тапшырабызмы, әллә итме?» – дим.

* * *

Татарлар аңлаша:

–Әнә теге кем әле ул?

–Ә бу теге ни бит!

–Ә-ә-ә... Шул икән шул.

«ШӘҺРИ КАЗАН» – СИНЕҢ ӨЧЕН, СИНЕҢ ТУРЫНДА 8 (917) 851-69-62

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ – БАШ МӨХӘРРИР ВАЗИФАСЫН БАШКАРУЧЫ
Илсөяр Илфруз кызы Вәлиуллина.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – Расиха Габделбәр кызы Исмәгыйлова.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 6338
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 691. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан, Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы